ТИМУР СӨЛӘЙМАНОВ: Яшьләр янына барырга, алар йөргән сукмаклардан атларга кирәк

> 5

КАДЕРЛЕ МАЛ Баш ветеринария идарәсе җитәкчесе урынбасары Илдар Нугуманов укучыларыбызның сорауларына җавап бирде

> 7

ЗӘЙНӘБ ФӘРХЕТДИНОВА: «Имиджны үзгәртәм, әмма чама хисен югалтканым юк»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 53 (29020) | Җомга | 14 апрель | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Илдар Мөхәммәтҗанов

УТСЫЗ ТӨТЕН

РОССИЯДӘ БАЛИГЪ БУЛМАГАННАРГА ВЕЙП САТУНЫ ТЫЙДЫЛАР

Узып баручы атна күптән көтелгән вакыйга белән истә калачак. Сишәмбе көнне Россия Дәүләт Думасы депутатлары балигъ булмаганнарга вейп сатуны тыю турында закон кабул итте. Электрон көпшә көйрәтү баласына да, анасына да гадәти хәлгә әверелеп бара иде. Хәзер ул тыелган җимешкә әйләнде. Яңа канун яшьләр арасында тамыр җәяргә өлгергән начар гадәттән котылырга ярдәм итәрме? «ВТ» хәбәрчесе шул сорауга җавап эзләде.

> 16

Ишетми калмагыз

Татарстанда 43 меңнән артыграк кешенең утлы коралы бар. Алар 75 меңләп төрле коралга ия. Росгвардиянең республика буенча идарәсендәге бүлек башлыгы Рамил Камалиев әйтүенчә, шуның 80 проценты чамасы (40 меңгә якын кеше) ау коралына ия. Аларда 65 мең берәмлек шома һәм кыска көпшәле ау коралы саклана.

Узган елда язгы ау чорында 900дән артыграк аучы тикшерелгән. Рейдлар нәтиҗәсендә 29 кеше коралыннан мәхрүм ителгән. Тикшерү чаралары быел да узачак. 2022 елда Татарстанда тиешле кагыйдәләрне бозган өчен барлыгы 483 берәмлек корал хуҗасыннан тартып алынган.

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында баласын беренче сыйныфка укырга кертү өчен ике атна эчендә 15 меңнән артыграк электрон гариза тапшырылган. Быел балаларны беренче сыйныфка алу ике этапта башкарыла. Үзе яши торган территориягә беркетелгән мәктәпкә баручылар, шулай ук үзләрен беренче сыйныфка алу өчен өстенлекле хокукка ия булучы сабыйлар 30 марттан 30 июньгә кадәр исемлеккә эләгәчәк. Уку йортын башка районнан сайлаган балаларның исемлекләре исә 6 июльдән 5 сентябрьгә кадәр төзеләчәк.

Казанның 175 нче гимназиясендә атыш оештырган Илназ Галәвиевне гомерлеккә ирегеннән мәхрүм итәләр. Татарстан Югары суды шундый хөкем карары чыгарды. Җинаять эшен тикшерү ярты елга якын барды. 600дән артыграк кеше зыян күрүче булып санала. Экспертиза Галәвиевне, үз акылында, дип таныган. Исегезгә төшерәбез: фаҗига 2021 елның 11 маенда булды. Илназ Галәвиев Казан гимназиясенә кереп, ут ачты. Фаҗигадә ике укытучының һәм җиде укучының гомере өзелде.

Сөенечле хәбәр!

2023 елның 10–20 апрель көннәрендә «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына ташламалы бәядән язылып була!

П2435 җомга саны — **Ташламалы бәя** 444 сум 54 тиен; гадәти бәясе – ~~512 сум 70 тиен~~

П2409 атнага дүрт тапкыр чыга — **Ташламалы бәя** 1051 сум 80 тиен; гадәти бәясе – ~~1227 сум 30 тиен~~

Реклама 16+

Районнарда ни хәлләр?

Зәй

Ринат Фәрдиев исемендәге ял паркының икенче өлешенә укытучылар агач утыртты. Бирегә хәзер «Педагоглар аллеясы» барлыкка килде. Бу Укытучылар һәм остазлар елы уңаеннан оештырыла. Игелекле эштә район җитәкчелеге дә катнаша. Аллеяга беренче каенны мәгариф идарәсе башлыгы утыртты. Бакча мөдирләре, мәктәп директорлары барлыгы 300 төп каен агачы, куак утырттылар. Укытучыларга «Легенды 17» студентлар отряды да булышты. Алар арасында булачак педагоглар бар.
(«Зәй хәбәрләре»)

Биектау

Район үзәгендәге өч урамга махсус операция геройлары исеме биреләчәк. Руслан Июдин Биектауның 3 нче урта гомуми белем бирү мәктәбендә укыган, Казан танк училищесына укырга кергән. Офицер дәрәҗәсен алгач, ул махсус хәрби операция башланганнан соң ук хәрби контракт төзи. Күрсәткән батырлыгы һәм кыюлыгы өчен вафатыннан соң Батырлык ордены на тәкъдим ителгән. Айрат Мөхетдинов һәм Данил Саитов Биектауның 2 нче мәктәбен тәмамлаганнар. Аларның гаиләләре Биектау районында яши.
(«Татар-информ»)

Азнакай

Район волонтерлары район хатын-кызлар оешмасы белән игелек ярминкәсе үткәрде. Шәһәребезнең уңган хуҗабикәләре, үзмәшгуль оста кондитерлар җан жылысын биреп әзерләгән эшләнмәләрен тәкъдим итте. Азнакайның киң күңелле, ихлас халкы алар янынан өзелмәде. Ярминкәдә җыелган акча районда яшәүче Гәрәевләр гаиләсендә тәрбияләнүче кечкенә сабыйны дәвалауга тотылачак. Теләге булган һәркем үз өлешен игелек тартмасына сала алды.
(«Азнакай»)

Бөгелмә

Шәһәрнең Салих Сәйдәшев скверында узган гаилә өмәсендә космонавт, Россия Герое Сергей Рыжиков та катнашты. Өмәгә хатыны һәм уллары белән килгән Бөгелмә мэры Линар Закиров бу эшкә өлеш кертүчеләргә рәхмәт белдерде. Өмәгә 300гә якын кеше җыелды. Алар арасында «Нефтеавтоматика» микрорайонында яшәүчеләр, хезмәт коллективлары, Бөгелмә администрациясе хезмәткәрләре, депутатлар, шәһәрнең Мактаулы гражданнары бар иде. Өмәләр атна саен 31 майга кадәр үткәреләчәк.
(Район хакимиятенең матбугат хезмәте)

Кайбыч

Чүпрәледә «Тарихта без эзлебез» дип исемләнгән шәҗәрәләр фестиваленең зона этабы узды. Анда Кайбыч, Чүпрәле, Тәтеш, Апас, Кама Тамагы, Яшел Үзән һәм Югары Ослан районнарыннан җиде гаилә катнашты. Төбәк бәйгесендә беренче урынны яулаган Гарәфетдиновлар республика этабында Кайбыч данын яклаячак.
(«Кайбыч таңнары»)

ЧИТ ИЛ ТҮГЕЛ

Рәис сәфәре

Чын дуслар! Минскида Татарстан белән Белоруссия арасындагы мөнәсәбәтләргә әнә шундый югары бәя бирделәр. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов җитәкчелегендәге республика делегациясе Белоруссиягә ике көнлек эш сәфәренә барды. Яклар ике арадагы товар әйләнешен ике тапкыр арттырмакчы.

rais.tatarstan.ru

Татарстан делегациясен Белоруссия Президенты Александр Лукашенко җылы каршы алды.

– Сезне, Рөстәм Нургалиевич, һәм безгә якын Татарстанны Минскида сәламләвемә шатмын. Без – күп еллар таныш, чын дуслар. Мин сезнең төбәкнең үсешен инде күптән кызыксынып күзәтәм. Ирешкән уңышлар сокландыра һәм безне Казан белән тагын да тырышыбрак эшләргә рухландыра. Моннан тыш, бездә бик эшлекле, нәтиҗәле мөнәсәбәтләр урнашты, ике арадагы элемтәләрне үстерү мөмкинлекләре гаять зур, – диде Александр Лукашенко.

Аның әйтүенчә, Татарстан җире Беларусь Республикасына бик тә охшаган. «Әгәр самолетта Татарстан өстеннән очуыны белмәсәң, бу нәкъ безнең Беларусь табигате дип уйлар идең», – дип белдерде ул.

Александр Лукашенко Татарстан делегациясенең Белоруссиягә эш сәфәрен дә югары бәяләде. Ул Ту-214 җитештерү өчен компонентлар китерү өлешендә хезмәттәшлек итәргә әзерлеген дә аерым билгеләп үтте.

Рөстәм Миңнеханов Александр Лукашенкога Татарстан делегациясенә игътибары өчен рәхмәт белдерде.

– Сезгә һәм Россия Президенты Владимир Путинга төбәк дәрәҗәсендәге хезмәттәшлекне хуплаганыгыз өчен рәхмәтлемен. Бу айда Белоруссия һәм Россия халыкларының бердәмлеге көне билгеләп үтелә. Чын күңелдән котлауларымны кабул итегез, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Рөстәм Миңнеханов Александр Лукашенкога Белоруссиядәге татар җәмәгатьчелегенә игътибары һәм ярдәме өчен аерым рәхмәт сүзләрен җиткерде. Татарстан Рәисе «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» турында да сөйләде һәм Белоруссиянең ислам дөньясы илләре белән хезмәттәшлеген исәпкә алып, республика делегациясен җыенга чакырды. Эш сәфәре кысасында Рөстәм Миңнеханов Белоруссия Премьер-министры Роман Головченко белән дә очрашты.

Татарстан сәнәгать һәм сәүдә министры Олег Коробченко сүзләренә караганда, 2022 елда Татарстан белән Белоруссия арасында тышкы товар әйләнеше 817 миллион доллардан артып китте. Сүз уңаеннан шунысын да әйтик: Александр Лукашенко әлеге күрсәткечне 2 миллиард долларга җиткерү өчен бөтен шартлар да булуын әйтте. Олег Коробченко белдергәнчә, республика автомобиль төзелеше, авиа төзелеш, нефть һәм газ химиясе, авыл хуҗалыгы, сәламәтлек саклау кебек тармакларда хезмәттәшлекне арттырырга тели. «Мәдәният, спорт һәм туризм буенча да элемтәләрне ныгытырга мөмкинлекләр бар», – дигән ышаныч бедерде ул.

Татарстанның КАМАЗ, «Татнефть», «Казан вертолет заводы», «Татспиртпром», «ПОЗиС» кебек зур оешма-предприятиеләре Белоруссия белән тыгыз хезмәттәшлек итә инде. Минскига эш сәфәре кысасында, безнекеләр «Минск трактор заводы», «Минск подшипник заводы», «Минск автомобиль заводы» вәкилләре белән дә очрашкан. Аерым алганда, Рөстәм Миңнеханов юл төзелеше, логистика, урман һәм авыл хуҗалыгы өчен махсус техника җитештерүче «Амкодор» компаниясендә, «Адвин» предприятиесендә булды. Ә Олег Коробченко «БЕЛАЗ» җитәкчелеге белән очрашты.

– Россия һәм Белоруссия хезмәттәшлеге ачыклык, тигезлек һәм үзара хөрмәт шартларында үсеш алуын дәвам итә, – диде Рөстәм Миңнеханов Россиянең Беларусь Республикасындагы Гадәттән тыш һәм Тулы вәкаләтле илчесе Борис Грызлов белән очрашуда. – Бу эштә Минскида Россиянең илчесе буларак, сезнең хезмәтегез дә бик зур. Татарстан белән Белоруссия арасындагы хезмәттәшлекне үстерү Россия – Белоруссия мөнәсәбәтләрен ныгытырга да ярдәм итәчәк дип өметләнәбез.

Үз чиратында Борис Грызлов Рөстәм Миңнехановка республика делегациясенең Илчелеккә килүе өчен рәхмәт белдерде. «Казанга эш сәфәрләремне җылы хисләр белән искә алам. Минтимер Шәриповичка иң изге теләкләремне җиткерегез», – диде ул.

Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, соңгы елларда Белоруссия Татарстанның тышкы сәүдә партнерлары арасында әйдәп баручыларның берсе булып тора. Хезмәттәшлек итү өчен мөмкинлекләр тагын да зуррак әле. Шуңа күрә эш сәфәренең төп максаты сәүдәне үстерүдән гыйбарәт.

Минскида Рөстәм Миңнеханов бу илдә яшәүче милләттәшләребез белән дә күреште. Белоруссиядә үткәрелгән соңгы халык санын алу мәгълүматларына караганда, бирегә 7 меңнән артык татар яши. Рөстәм Миңнеханов аларның туган телләрен һәм мәдәниятен саклауга керткән зур өлешләрен билгеләп үтте. Рәис киләсе елның сентябрендә Минскида Татарстан мәдәнияте көннәре узачагын да әйтте.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Республиканың агросәнәгать комплексы өчен квалификацияле белгечләр әзерләүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Саба аграр көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директоры **Бикмөхәмәтов** Закирҗан Минемулла улы, халык сәламәтлеген саклау эшенә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Россия өзлексез һөнәри белем бирү медицина академиясе» федераль дәүләт бюджет өстәмә һөнәри белем бирү мәгариф учреждениесе филиалы – Казан дәүләт медицина академиясенең нурланыш ярдәмендә диагноз кую кафедрасы мөдире **Михайлов** Марс Константинович **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Финанс-икътисад эшчәнлегендәге казанышлары һәм республиканың нефть сәнәгатен үстерүгә өлеш кертүе өчен В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыяте генераль директоры каршындагы башкарма аппаратның икътисад идарәсе башлыгы **Гайфуллина** Резеда Рәүф кызы, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытудагы, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклаудагы казанышлары өчен Татарстан Республикасы Казан шәһәре прокурорының өлкән ярдәмчесе **Нуруллин** Илдар Динар улы, мәгариф өлкәсендәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Казан халык сәнгать һөнәрчелеге техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү мәгариф учреждениесе директорының укыту-производство эше буенча урынбасары **Гаязова** Минзифа Рафаил кызы, һөнәри эшчәнлектәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең хезмәтне оештыру һәм нормальлаштыру буенча әйдәүче инженеры **Ногманова** Резеда Рәүф кызы, республиканың нефть химиясе сәнәгатен үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «ТАНЕКО» акционер җәмгыяте генераль директоры **Сәлахов** Илшат Илгиз улы, транспорт өлкәсендә күпьеллык намуслы хезмәте өчен Түбән Кама шәһәре «КАМАтранссервис» транспорт-экспедиция фирмасы» акционер җәмгыятенең механикалаштырылган колоннасы автомобиль йөртүчесе **Ханов** Ралиф Хәләф улы Татарстан Республикасының **«Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен хезмәт ветераны **Баязитов** Кеазым Садыйк улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

«ДСК» махсуслаштырылган төзү эшләрен башкаручы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры (Казан шәһәре), «Трансюжстрой» махсуслаштырылган төзү эшләрен башкаручы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры (Белгород шәһәре) **Рамазанов** Рөстәм Габделфәрит улына, «Газстрой» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Сафиуллин** Салават Рәис улына, «Татарстан Республикасының инженерлык челтәрләре капиталь төзелеше һәм энергияне сакчыл тоту технологияләрен үстерү идарәсе» акционер җәмгыятенең җитештерү-техник бүлеге баш белгече **Унжакова** Татьяна Александровнага **«Татарстан Республикасының атказанган төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

ХӨКҮМӘТ ХИСАП ТОТАЧАК

Алтынчы чакырылыш Дәүләт Советының кырык өченче утырышы 20 апрельдә узачак. Мондый карар парламент Президиумы утырышында кабул ителде.

Депутатлар 22 мәсьәлә, шул исәптән 7 республика законы проектын, 9 федераль закон проектын һәм Мурманск өлкәсе Думасының РФ Хөкүмәте Рәисе Михаил Мишустинга мөрәҗәгатен карарга планлаштыралар. Анда сүз күпфатирлы йортлардагы урыннар һәм торак йортлар милекчеләренә һәм алардан файдаланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында бара.

Утырышның көн тәртибендәге төп мәсьәлә Татарстан Министрлар Кабинетының 2022 елдагы эшчәнлеге турында хисап булачак. Документ Дәүләт Советына 7 апрельдә кертелгән иде, һәм ул профильле юнәлешләр буенча барлык комитетларда каралды. Парламент утырышында Премьер-министр Алексей Песошин чыгыш ясаячак.

Дәүләт Советы Секретаре Лилия Маврина билгеләп үткәнчә, кырык өченче утырышта беренче укылышта шулай ук дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында (республика законын ТР Конституциясенә туры китерү максатларында эшләнгән, хакимиятнең башкарма органнарын оештыруның һәм эшчәнлегенең хокукый нигезләрен билгели), дәүләт граждан хезмәте турында, Дәүләт Советы депутаты статусы турында, Дәүләт вазыйфалары турында, автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге, автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыруның аерым мәсьәләләре турында закон проектлары каралачак.

Утырышта депутатлар игътибарына «2022 елда Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларының торышы һәм үсеше турында» доклад тәкъдим ителә. Бу нисбәттән республика Иҗтимагый палатасы рәисе Зилә Вәлиева чыгыш ясаячак.

Президиум утырышында башка мәсьәләләр дә каралды. Утырышны Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов үткәрде.

Күңел халәте бу

Россиядә 2006 елдан бирле һәр ел саен 13 апрельдә Меценат һәм хәйрияче көне билгеләп үтелә. Бу уңайдан Татарстан Премьер-министры Алексей Песошин республикада яшәүчеләрне котлады.

«Мохтаҗларга ярдәм кулы сузучылар, теләсә кайсы изге эшкә үзләреннән өлеш кертергә тырышучылар, файдалы иҗтимагый эшчәнлеккә булышучылар көне бу, – диелә котлауда. – Татарстанда хәйриячелекнең саллы тарихы бар. Республика фәкыйрьләрнең, сырхаулар, аз керемлеләр һәм авыр тормышта яшәүчеләрнең хәленә керергә әзер торучы кешеләргә һәрвакыт бай булды.

Гадәттәгечә, эре сәнәгать предприятиеләре зур хәйрия эшләре алып бара. Кече бизнес предприятиеләре, коммерциясез оешмалар, гади кешеләр дә хәйриячелеккә елдан-ел күбрәк тартыла. Зур финанс мөмкинлегенә ия булулары турында сөйләми бу. Аларның күңел халәте шундый.

Бүген волонтерлык хәрәкәтен дә искә алып үтми мөмкин түгел. Йөзләрчә егет-кыз үз көчен һәм вакытын хәйрия проектларында эшләүгә багышлый. Алар ихтирам-хөрмәткә лаек. Гәрчә игелеклелек дан-шөһрәт алу, җәмгыятьтә танылу өчен эшләнмәсә дә.

Барлык меценатлар, хәйрияче һәм волонтерларга изге күңелле, олы йөрәкле булганнары өчен чын күңелдән рәхмәт белдерәсем килә. Сезнең үрнәк кешеләрдә уңай энергия уята, изге эшләрдә катнашудан күңелгә рәхәтлек хисе алуга әйрәтә.

Республикада, гомумән бөтен Россия күләмендә меценатлар, хәйриячеләр саны елдан-ел артсын иде!»

САКСЫЗЛЫК БӘЯСЕ

Яз башыннан коры үләнгә ут кабып, Татарстанда 393 янгын чыккан. Былтыр ел буена 1214 очрак теркәлгән. Билгеле булганча, бу атнада Актаныш районында берьюлы 5 йорт янып юкка чыкты.

«Татар-информ»

Сан

Татарстанда ел башыннан **1235** янгын очрагы теркәлгән. Бу – узган елгыдан **41,8** процентка күбрәк. Утта **39** кеше һәлак булган, **60** кеше тән җәрәхәте алган.

Бу саннарны журналистларга Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан буенча Баш идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эш идарәсе җитәкчесе Максим Трущин җиткерде.

– Кар эрүгә, чүп-чар баш калкыта. Көннәр җылынгач, кешеләр җыештыра башлый. Йорт тирәләрен, бакчаларын тәртипкә китерергә тотыналар. Нәкъ шушы вакытта үләнгә ут кабу очраклары арта да инде, – ди ул. – 393 очракның 82се Түбән Камада районында теркәлде. Әлмәт районында – 35, Чаллыда – 29, Тукай районында – 30, Зәйдә – 20, Чирмешәндә 18 тапкыр үлән януын җиткергәннәр. Янгын сүндерүчеләр тәүлегенә 60ар шундый хәбәр ала. Коры үлән янып, аның йортларга күчү очраклары да булды. Әйтик, Актаныш районының Буаз Күл авылында 10 корылма янды. 5есе – торак йортлар. Ул йортларның икесендә кеше тора, өчесе – ташландык хәлдә. Бу йортлардан берни калмады. Беренчел фаразлар буенча, янгын билгесез кешенең ут белән саксыз эш итүе аркасында килеп чыккан.

Сүз уңаеннан, 10 апрельдә булган куркыныч вакыйга турында матбугат чаралары төрлечә хәбәр бирде. «ВТ» хәбәрчесенә 83 яшьлек Әспира Нәбиуллинаның кызы Раушания дә, йорты янып көлгә әйләнгән Зөлфәт Фазлыйәхмәтов та утның бакча артыннан килүен әйткән иде. Ярый әле үзләре зыян күрмәгән. Янгынның олы яшьтәге хатын-кызның саксызлыгы аркасында килеп чыгарга мөмкин икәнен әйтүчеләр дә бар. Белгечләр исә ашыкмаска киңәш итә. Әлегә тикшерү бара.

Максим Трущин тагын бер кат сак булырга кушты.

– Әлегә чүп-чарны тирәнлеге 30 сантиметрдан ким булмаган, диаметры 1 метрлы чокыр казып яндырырга рөхсәт ителә. Чыбык-чабык яндырганда диаметрны 3 метрга җиткерергә кирәк. Ачык ут корылмалардан – 50 метр, агачлыктан 100 метр читтә булырга тиеш. Учакны тиешенчә сүндереп китәргә кирәк, – ди ул. – Ә 17 апрельдән 10 майга кадәр Татарстанда чүп яндыру, шашлык пешерү бөтенләй тыела. Янгын куркынычсызлыгы режимы кертелгән вакытта 116 торак пуктта,75 бакчачылык ширкәтендә, 84 балалар ял лагере аеруча контрольгә алыначак.

Янгынга каршы махсус режим кертелгән вакытта учак кабызырга, каты көнкүреш калдыклары, коры үлән һәм чүп-чар яндырырга ярамый. Моннан тыш, табигатьтә ял иткән вакытта, шулай ук бакчачылык ширкәтләре территориясендә ачык утта ризык әзерләргә рөхсәт ителми. Пиротехника кулланy да тыела.

Янгын кагыйдәләрен бозган өчен штраф каралган. Янгынга каршы режим кертелгән вакытта тәртип бозучы гади кешеләргә – 10 меңнән 20 мең сумга кадәр, вазыйфаи затларга – 30 меңнән 60 мең сумга кадәр, эшмәкәрләргә – 60 меңнән 80 мең сумга кадәр, юридик затларга 400 меңнән 800 мең сумга кадәр штраф салыначак.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Спорт

rubin-kazan.ru

Рәхимов итегез!

«Рубин»да янә тренер алмаштырдылар. Әле узган ел ахырында гына баш тренер вазыйфасына килгән Юрий Уткульбаевның урынын аннан күпкә тәҗрибәлерәк Рәшит Рәхимов алды. Иң кызыгы: киткән тренер кулы астында Казан командасы бер мәртәбә дә җиңелмәде. Дөрес, җиңү тәмен дә онытып җибәрде.

Башкала клубларында баш тренерларга һәрвакыт үзгә мөнәсәбәт булды. Ни булса да, аларны ашыгып алмаштырмаска, җиде кат үлчәп эш итәргә тырыштылар. Әмма соңгы вакытта бу гадәт юкка чыкты. «Ак барс»та, әйтик, сезон барышында остазны алмаштыру соңгы тапкыр 2004 елда ук булган иде. Бу сезонда янә шундый адымга бардылар: Олег Знарок урынына Зиннәтулла Билалетдинов килде. «Рубин»да исә тагын да алгарак киттеләр: быелгы сезонда команда инде өченче тренер белән эшли. Леонид Слуцкий урынына килгән Юрий Уткульбаев та эшен ахырына җиткерә алмады.

Иң кызыгы шул: узган елның декабрендә эшли башлаган Юрий Уткульбаев кулы астында уйнаганда «Рубин» бер мәртәбә дә оттырмады. Казан командасы 8 рәсми матчның 4есендә җиңүгә ирешсә, калганнары ничьяга тәмамланды. Бер караганда, тренерны эшеннән алу сәер кебек. Икенче яктан игътибар итсәк, быел яз узган 4 очрашуда «Рубин» бер тапкыр да җиңүгә ирешә алмады. Нәтиҗәсе уенны баш тренерның командадагы танылган уенчылар белән уртак тел таба алмавы аркасында дип аңлатучылар да бар. Ничек кенә булмасын, җанатарларына быел ук премьер-лигага әйләнеп кайтырга вәгъдә биргән командага килешә торган хәл түгел. Иң көчлеләр сафына әйләнеп кайткан очракта, киләсе сезонда «Рубин»ның катлаулы уеннар көтә. Анда исә Юрий Уткульбаевның тәҗрибәсе җитеп бетмәскә мөмкин. Шуңа күрә клубтагы яңа җитәкчелекнең киләсе сезонга әзерлекне хәзердән үк башлавы ихтимал.

Казан клубында тренер алмашыначагы турындагы хәбәрләр әле узган атнада ук чыккан иде. Кызып китеп, кайберәүләр «Рубин»га Корбан Бәрдыевнең кайтачагын да әйтеп ташлады. Билгеле булганча, Иранннан кайткач, «Сочи»да эшли башлаган остазны 1 ай дигәндә эшеннән алдылар. Казанга исә Бәрдыевны түгел, ә соңгы арада «Матч ТВ» каналында эшләгән Рәшит Рәхимовны чакырдылар. Заманында «Памир» (Дүшәнбе), «Спартак» (Мәскәү), «Вальядолид» (Испания), «Локомотив»та (Мәскәү), аннары Австриядәге «Аустрия», «Адмира Ваккер» һәм «Рид» командаларында туп типкән белгеч тренерлык эшенә 2002 елда алынды. «Адмира Ваккер» (Австрия), «Амкар», «Локомотив», «Ахмат», «Уфа»ны җитәкләде ул. Пермь һәм Грозныйдагы эшчәнлегенә яхшы бәя бирсәләр, Мәскәүдә көтелгән нәтиҗәгә ирешә алмады. Уфада да аны сагынып искә алучылар күп түгелдер. Һәрхәлдә, Рәшит Рәхимов киткәч, команданың кайбер уенчылары журналистлар белән аралашканда аның турында мактау сүзләре әйтмәде.

«Ак барс» Гагарин Кубогы финалында ЦСКА белән очрашачак. Беренче ике матч 17 һәм 19 апрельдә Казанда узачак. Көндәшләр 2018 елда да финалда очрашып, «Ак барс» серияне 4:1 исәбенә үз файдасына төгәлләгән иде. Бу – Казан командасының бишенче финалы. ЦСКА бишенче ел рәттән Гагарин Кубогы өчен көрәшә.

Әйтеп кенә бактым

Каен

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Яз – яз инде ул, сиздермичә генә бөтен күзәнәкләргә үтеп керә, күңелгә дәрт, тормышка ямь өсти. Бөтен тереклек кышкы йокыдан уянганда, үзем дә яңадан туган кебек булам. Язгы кояш белән бер-беребезгә күз кысышабыз. Мин аңа: «Шифалы нурларың өчен рәхмәт!» – дим. Ә ул миңа тагын да кинәрәк итеп елмая, әйтерсең лә озын гомер тели. Һәрхәлдә, мин аннан шуны сорар идем, чөнки бөтен тереклек язмышы кояшка бәйле.

Яз галәмәтләренә сокланып, кибеткә таба атлаганда, асфальтта җыелып торган су күрдем. Инде ничә көн яңгырның әсәре дә юк, чалт иткән аяз көннәр! Каян килгән бу су? Шул вакыт башыма тамчы тамды. Монысы каян килеп чыкты тагын? Башымны күтәреп караган идем, каенның бер ботагын сындырганнар да, шуннан каен суы тама икән. Яшьрәк чагым булса, үрмәләп менәр идем дә, ярасын бәйләр идем каен кызының, тик хәзер бу минем кулдан килерлек түгел шул. Сынган ботак шактый биектә.

Инде менә дүртенче көн шул каен янынннан узам, ә ул һаман елый, аның күз яшеннән барлыкка килгән күлләвек тә кибеп бетә алмый. Каен ботагын сындырырга кайсы хәерсезенең кулы күтәрелде икән?

Балачак, үсмер чак искә төшеп китте. Яз җитүгә, каен суы эчәргә су буена төшә идек без. Дөрес, каеннар инеш буенда үк түгел, өстәрәк, Мәрьям апаларның бакча башыннан чишмәгә төшә торган сукмак тирәли үсеп утыралар иде. Без шул каен кызларын кочаклап, үбеп үстек, диярге була. Каен суы эчәр өчен аның ботакларын сындырмадык, кәүсәсенә балта чапмадык, пычак белән тирән яра эзләре калдырмадык, бары тик кадак белән кечкенә генә тишек ясый идек тә, каенны кочаклап, ширбәтен суыра идек. Кайберәүләр шешәләргә дә җыйгалады. Әмма киткәндә кадак тишегенә агач бөке тыгып, балчык белән сылап китә идек. Янәсе, каен суы агып бетмәсен. Безгә моны авыл картлары өйрәтте. «Каен суы кеше каны шикелле, агып бетсә, агач корый», – дип әйтә торганнар иде.

Яз килүгә бөтен җиһан шатланганда, каен нигә елый икән? Халык телендә «каен кайгылы була» дигән сүзләр бар, алар «каен» һәм «кайгы» дигән сүзләр бераз авазлаш булганга гына әйтелмидер. Халык җырларында, шигырьләрдә дә каен күбесенчә моң, аерылу, кайгы хисләре белән телгә алына. Югыйсә башка агачлар арасында каен – ап-ак кәүсәле бердәнбер агач. Ә ак бәхет, шатлык билгесе бит инде. Ни өчен «... ялгыз каеннардан ялгыз каласың, бәгырькәем» дип җырлыйбыз икән без? Олпат шагыйребез Хәсән Туфан да үзенең бер шигырендә:

Яфраклары яшел ак каенга
Юл буеннан аклар килделәр.
Ак каенның ярлы авылдашын
Билбавына асып киттеләр, –

дип язган иде.

Халык бу сүзләрне көйгә салып, җырлап та йөрде әле. Оренбург татары, композитор, скрипкачы Мәсәлим Вәлиевнең «Ак каен» көенә җырлады ул аны. Бу җырны безнең буын: «Яфраклары яшел ак каенның, хәтфә җәйгән кебек һәр ягы...» – дип, Зыя Ярмәки сүзләренә җырлап үсте, мәктәп программасында да бар иде бугай ул. Без аны язын каен тирәли җитәкләшеп йөреп җырладык. Укытучы апа шулай кушты. Якты, матур, яз кебек җылы җыр ул. Хәзер балалардан бик ишеткән юк. Балалар хәзер күбрәк мәхәббәт турында җырлый бугай һәм каеннарга, табигатькә мәхәббәт турында түгел.

Бу язмамны тәмамлар алдыннан яңадан каен янына барып килдем. Елаудан туктаган иде ул, димәк, түгәсе яше түгелеп беткән. Үзенә яшәү көче бирерлек ширбәте калгандырмы-юкмы – анысын белеп булмый, киләчәк күрсәтер. Сагыштан саргая башласа, яшәү көче беткән дигән сүз.

Мин исә үземне булырга торган бер фаҗигане шаһиты кебек хис итәм, оят та, уңайсыз да миңа. Каен кызының үлгәнен карап торам кебек тоелып китә. Яман эшкә юл кую – үзе үк зур гөнаһ, диләр, ә мин аны булдырмауның бер-бер чарасын таба алмадым, чарасызлыктан гаҗиз идем. Үткән-сүткәннәргә каен ботагын күрсәтеп, берәр нәрсә эшләп булмасмы, дип әйтеп тә карадым. Минем көлделәр генә. «Обидно, конечно», – диючеләр булды үзе. Миңа да обидно шул, каен өчен дә, и за вас, кәнишне.

АРКАДАШЛАР ЭЗЛӘГӘНДӘ

Америка Кушма Штатларының элекке Президенты Трамп, агымдагы хәлләрне бәяләп, үзенең аккаунтына «Өченче Бөтендөнья сугышы» дигән язу элде, диделәр. Чынлап та, дөнья сәясәтенең спирале зур сугышка таба бөтерелә. Дәүләтләр идарәсен югалткан локомотив кебек зур катастрофага таба ыргыла.

Чыгышы белән поляк булган америкалы Збигнев Бжезинский 1997 елда: «Бөек шахмат тактасы: Американың хакимлеге һәм аның геостратегик императивлары» дигән китап язган иде. СССРны таркатуның стратегиясен эшләгән һәм аны уңышлы тормышка ашыруда катнашкан Бжезинский Америка өстенлеге XXI гасырда да дәвам итәр һәм уен кагыйдәләре гел Вашингтонда эшләнер дип уйлаган иде. Моннан ике елга якын элек без американнарның Әфганстаннан чыгып качуын сурәтләгәндә: «Бу гадәти вакыйга гына түгел, дөнья тарихының яңа бите ачылды һәм без киләчәктә аңа бәйле зур вакыйгаларның шаһиты булырбыз әле», – дип язган идек. Һәм ни күрәбез: АКШ гегемонлыгы акрынлап кына сәхнәнең арткы планына күчә, Вашингтон дилбегәне бик еш кулыннан төшереп җибәрә, бөтенләй уйламаган дәүләтләр үзләрен уен кагыйдәләрен үзгәртүчеләр итеп игълан итә, кичә генә үзара дошман булган көчләр аркадашлык итә башлый.

Төркиядә яңа гына «мөселман дөньясының иң куәтле хәрби корабы» дип тамгаланган TCG ANADOLU очкыч йөртүче судносы илнең хәрби-диңгез көчләре составына кабул ителде. 231 метр озынлыктагы, 32 метр киңлектәге корабны суга төшергәндә, ил башлыгы Әрдоган: «Без уен кагыйдәләрен үзгәртүче ил булачакбыз», – дигән сүзләр әйтте. Төрекләр, чынлап та, хәрби куәтләрен нык үстерә. Икътисадый авырлыклар кичерүгә карамастан, 25 миллиард долларлык хәрби бюджетларын 75 миллиардка җиткерергә җыеналар. Төрек хәрби-сәнәгать комплексы даими рәвештә технологик яктан тиңе булмаган яңа хәрби коралларны табадан төшерә һәм экспортлый.

Хәрби куәт ягыннан америкалылар, әлбәттә, лидерлыкны саклый, ләкин аларның хәрби машинасы инде Вашингтонга моннан берничә ел элек булган глобаль йогынтыны тәэмин итә алмый. Күптән түгел генә Согуд Гарәбстанының тәхет варисы Мөхәммәд бин Сәлмән (чынлыкта, ил белән идарә итүче лидер) үзенең кәрәштәшләренә: «Моннан соң АКШка яраклашып яшәү мәнфәгатьләремә керми», – дигән сүзләр әйтте диделәр. Байден командасы, күпме генә тырышмасын, Әр-Риядка ачкыч таба алмый. Агымдагы вазгыятьтә «кара алтын» державасы булган илгә сүзе үтмәү Вашингтонга кыйммәткә төшә. Россияне икътисадый яктан тезләндерү, Кытайны йөгәндә тоту бары тик гарәпләр аркадашлыгы белән генә була ала. Корольлек исә көтмәгәндә шундый борылыш ясады: Американың бөтен стратегиясен җимереп ташлый язды. Пекин белән аркадашлык юлына басты. Гарәп нефте юаньнарга сатыла башлады. Кытай арадашлыгы белән Иран һәм Согуд Гарәбстаны үзара килешүләр һәм аларның хезмәттәшлеге башланып килә. Ул килешү шунда ук үзенең җимешләрен күрсәтте: озак еллар буе Йәмәндә барган сугыш туктатылды. АКШның Үзәк разведка идарәсе директоры Бернс бу уңайдан зур канәгатьсезлек белдерде. Ул да күптән түгел генә Согуд Корольлегендә булып китте, әмма уңышка ирешмәде, күрәсең. Фарсы култыгы илләре белән аркадашлык Кытайга зур мөмкинлекләр ача. Күк асты иле АКШ йогынтысыннан чыкты гына түгел, үзен дөньяның икенче полюсы дип игълан итә башлады һәм Америкага каршы блок төзү белән мәшгульләнә.

Франция Президенты Макронның әле генә Кытайга булып үткән визитын искә төшерегез әле. Макрон Пекинга Сины Украина ягына аударырга дип барган иде. Күк асты илендә аны шундый итеп зурладылар: Парижга кайткач, ул бөтенләй сәер сүзләр әйтеп ташлады. «Европа АКШтан, аның долларыннан, сәясәтеннән, коральннан бәйсез булырга тиеш», – диде. Дөрес, аның бу белдерүен Парижда элиталар сөенеп кабул итмәде: хурлыкка калган ахмак дип атаучылар булды, мыскыллы «макронлаштыру» дигән фигыль уйлап чыгардылар. Ләкин Европа лидерларының соңгы вакытта Кытайга ешлауларын искә төшерик. Кытайның тышкы сәясәтен билгеләүче Ван И да күптән түгел генә Европада сәяхәт итеп кайтты. Сәхнә артында нинди сөйләшүләр баруын без белмибез. Европа – АКШтан кала Кытайның иң мөһим сәүдә партнеры, аларның үзара сөйләшүләр алып баруы, уртак тел табарга омтылуы гаҗәп түгел. Сөйләшүләрнең Вашингтонга каршы булу ихтималлыгы шаккатыра.

Вашингтон белән Пекин мөнәсәбәтләре исә тәмам бозылып бетте. Байден белән Цзиньпинның Индонезиядә G20 кысасында очрашуыннан соң, ике держава арасында мөнәсәбәтләр җылынып төсле иде. Ләкин җепшеклек урынына кырау төшүе күзәтелә. Кытай АКШка басым ясауның яңа юлларын эзли. Җирдә сирәк очраучы металларның 98 процентын үз кулларында тотучы кытайлар, милли куркынычсызлык максатыннан, АКШка сирәк очрый торган магнитларны экспортлауны туктатырга җыена.

pixabay.com

Кытайның соңгы вакытларда ирешкән технологик уңышлары үзен бәйсез тотарга мөмкинлек бирә. Күк асты иле яңа буын аккумуляторлар җитештерү буенча лидерлыкны үз кулына алды. Литий-ион аккумуляторлар урынына натрий-ион батареялар җитештерүне җәйга салырга әзерләнә. Литий сирәк очрый һәм кыйммәт, натрий исә күп табыла һәм арзан. Япон белгечләре, чин аккумуляторлары якындагы елларда дөньяны яулап алыр, дип уйлыйлар. Пекин ясалма интеллектны куллану буенча да лидерлыкны үз кулларында тоталар. Стэнфорд университеты ясалма интеллектка ышаныч белдерү буенча кытайлар беренче урында торалар, дигән нәтиҗә ясаган. Икенче урында кемнәр дип уйлыйсыз? Французлармы, немецлар яисә россиялеләрме? Юк, Согуд Гарәбстаны.

Дөньяның технологик үсеш «юрган»ы нык үсешкә ирешкән илләрдән өченче дөнья илләре дип саналган мәйданнарга таба күчә. The Washington Post газетасы үткән көннәрдә: «Мисыр Президенты Сиси, яшерен рәвештә Россиягә озату өчен, 40 мең ракета җитештерергә әмер бирде», – дип язды. Рәсми Вашингтон расламады ул хәбәрне, без дә Россия Мисыр ракеталарына заказ биргән дип әйтергә җыенмыйбыз. Әмма кайчандыр корал импортына мохтаҗ булган илләрнең ракета җитештереп экспортлау мөмкинлеге булу «Бөек шахмат тактасы»нда диспозицияләрнең Бжезинский планлаштырганча формалашмавын раслый. Дәүләтләр бүген Россия – Украина конфликты тирәсендә һәм шуңа мөнәсәбәттә блокларга берләшә.

Бу юнәлештә ике мөһим моментны аерып чыгарыйк. АКШ бу юлы, санкцияләр кертеп, үз дошманын глобаль рәвештә изоляцияли алмады. Киресенчә, блокада идеясе Америка сәясәтенең йомшак урынына әверелде. Икенчесе шул: кайчандыр дөнья сәясәте читлегендә кон күргән дәүләтләр глобаль лидерлыкка дәгъва белдерә һәм моны исәпкә алмау коточкыч ялгышларга китерә. 11 апрельдә япон Премьеры Кисида Бразилия Президенты Лула белән телефоннан сөйләште. Ул Луланы быел май аенда Хиросимада булачак G7 саммитында катнашырга чакырды. Лула Россиягә һәм Кытайга якын позициядә тора. Күрәсең, көнбатышлылар (кояш чыгышы иле булса да, Япония шул блокка керә) Бразилияне үз якларына аударырга җыена.

Мәскәүнең (һәм Пекинның да) төрекләр һәм Якын Көнчыгыш белән аркадашлык итүе алар өчен дөрес стратегия һәм тактика дип саныйм. Әмма вазгыять тиз үзгәрүчән бит. Кайчандыр безгә япон кешесенә «дефицит» сүзенең ни икәнен аңлатып булмый дип әйтәләр иде. Бүген Кояш чыгышы илендә моңарчы күрелмәгән дәрәҗәдә тавык йомыркасы җитешми. Илнең төп икътисадый газетасы «Никкэй» моны «куллану базарының шогы» дип атады. Рестораннар менюдан йомырка куланылып әзерләнә торган ризыкларны алалар, чөнки бәяләр күтәрелеп, клиентларны югалтудан куркалар. Кем уйлаган, кем уйлаган?! Бу дөнья – Тукайның «Басыч»ы шул: бүген өстә булган басмалар иртәгә аска төшмәс дип гарантия биреп булмый.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

ТИМУР СӨЛӘЙМАНОВ:
«ДУЛКЫНГА КАРШЫ БАРЫП БУЛМЫЙ»

Яшьләр янына барырга, алар йөргән сукмаклардан атларга кирәк. Татарстан Рәисе ярдәмчесе, «Алдынгылар хәрәкәте»нең республикадагы бүлеге җитәкчесе Тимур Сөләйманов фикере бу. Аның белән яңа хәрәкәтнең пионериядән аермасы, замана баласында теләк һәм җаваплылык, бурыч һәм ирек турында сөйләштек.

«Алдынгылар хәрәкәте»нең республикадагы бүлеге матбугат хезмәте

:: Тимур Җәүдәтович, яңа оешма турында сүз чыгуга аны «яңа пионерия» дип атый башладылар. Аермасы нәрсәдә?

– Оешманы «яңа пионерия» дип атаулары гадәти. Олы яшьтәгеләр бу сүзне сагыну-сагыш, җылылык белән әйтә. Чөнки ул алар өчен яшәү, фикерләү рәвеше иде. Анда булган образлар, геройлар, дуслар бала чакларын искә алалар. Пионерия – яшьләрне тәрбияли торган социаль технология дә. Яхшылыкка гамәлсез берничек тә өйрәтә алмыйсың. Бөтен нәрсә хәрәкәт белән генә эшләнә. Ә яңа заман яшьләре пионериянең ни икәнен белмиләр. Бүгенге заманның эчтәлеге бөтенләй икенче төрле. Балага, яшьләргә карата мөнәсәбәт моннан 30, 40 яки 50 ел булганы белән чагыштырганда катлаулырак. Хәзерге яшьләр онлайн тормышта да яши, алар виртуаль белән чынбарлыкны аермый. Виртуаль дөньядагы мөнәсәбәтләрне көндәлек тормышта да тоя, ул аларга зур йогынты ясый. Җавапны шуннан эзлиләр.

> Шуңа күрә, бик теләсәләр дә, бүген кабат пионерия кору мөмкин түгел. Ул дөрес тә булмас иде. Чөнки бу хәрәкәт яшьләргә якын булырга, ә моның өчен алар аны үзләре уйлап чыгарып, тулыландырып, әйдәп барырга тиеш. Шулай эшләмәсәң, коры, формаль оешма килеп чыга. Чын хәрәкәтне административ алым белән генә кора алмыйсың.

– Бүгенге шартларда бигрәк тә...

– ...чөнки иң зур кыйммәт – баланың игътибары. Аны кызыксындырырга кирәк. Шуннан соң гына ул теләп катнаша һәм әлеге хәрәкәттәге кыйммәтләрне кабул итә башлый. Әмма пионериядәге файдалы, сыйфатлы һәм эшли торган алымнар, мисаллар күп булды. Әйтик, шул ук атрибутика, җырлары-шигырьләре белән әлеге оешма мохите булдырылган иде. Мәктәптә – пионерлар. Алар – синең сыйныфташ кына түгел, синең белән бер дулкындагы дуслар да. Укытучың да кайчандыр пионер булган кеше, димәк, ул – остаз гына түгел, сине аңлый торган кеше дә әле. Лагерьга барсаң – пионер. Телевизорны кабызсаң, алар турындагы фильм. Китапны ачсаң, пионерлар турында укыйсың. Тирә-яктагы мохит 360 градуска шушы хәрәкәткә бәйле. Балада, әлбәттә, мин дә пионер булам дигән хис туа. Бүген моны эшләү авыррак. Чөнки мәгълүмати мохит тулган. Ләкин була. Ничек итепме? Хәрәкәт, гамәлләр аша. Карап утыру түгел, баланың анда үзе дә катнашуы кирәк. Үзең пешергән бәлеш әнинекеннән, хатынныкыннан тәмлерәк булмаса да, кадере күбрәк. Һәм тәҗрибә дә арта.

Аннары пионерия партиягә дә бәйле иде. Башта октябрят буласың, аннары пионер, комсомол килә. Без партия оешмасы түгел, төп эшебез яшьләрне тиешле кыйммәтләр белән тулыландырып, принципларны кулланып, бер-берсе белән дуслаштырып, таныштырып, тормышка әзерләү. Тормышта мәгълүмат бик күп. Шул шартларда бала тотрыклы кеше булып өлгерергә тиеш. Гаиләнең генә кулыннан килә торган эш түгел бу. Аның тирәсендә мохит, кешеләре шундый булырга тиеш. Дөрес башкарып чыга алсак, әлеге хәрәкәт аша җәмгыятьне үзгәртә алырлык яңа буын яшьләре үсеп җитәчәк.

:: Бала бу оешмага ничек керәчәк?

– Иң беренчесе, үзе теләп.

:: Ә ул теләк каян барлыкка килә?

– Командабыз белән актив мәгълүмати эш башладык. Атна саен 4–5 районга барып, укытучылар-директорлар белән очрашабыз. Бу аларга өстәмә эш, яңа бирем түгел – шуны аңлатабыз. Бу, киресенчә, аларга ярдәм булачак. Чөнки һәр мәктәптә теләге, тәкъдиме булган яшьләрне берләштерүче хәрәкәт оешса, бу остазларга – таяныч, үзен таба алмаган яшьләргә этәргеч булачак. Бу оешма мәктәп, колледж кына түгел, үсмерләр клублары, яшьләр үзәкләре, сәнгать мәктәпләре, киләчәктә спорт мәктәпләрендә эшләячәк. Мондый клублар кайда бала бар – шунда оешачак. Актив яшьләр бар, алар күп. Әлеге хәрәкәт эшләп китсә, аңа башкалар да кушылачак. Бу – активистлар хәрәкәте түгел. Бу – белемгә, хәрәкәткә омтылган, кызыклы һәм файдалы эшчәнлек аша яңа дуслар табарга теләгән кешеләр хәрәкәте. Шөкер, андыйлар күп.

Балалар өчен чаралар күп. Ләкин нәтиҗәсе без теләгән дәрәҗәдә түгел. Бала аларны «акыл өйрәтү» дип кабул итә. Без исә «үзебез оештырдык, катнаштык» дигән фикер, җаваплылык хисе барлыкка килсен дип телибез. Аларны кулларыннан тотып эшләтәсе түгел, тәкъдимнәре белән үзләре киләчәк.

:: Ирекле хәрәкәт дип әйттегез, әмма безнең эшне арттырып үти торган гадәт тә бар. Бөтен баланы бер оешмага кертү омтылышы булмасмы?

– Яшьләр күп булсын. Әмма эше тиз булмасын. Мәҗбүри булса, ясин чыгып, бу эшне шунда тәмамларга да була инде. Шуңа күрә аңлатабыз, районнарга йөрергә, мәктәпләргә барып җиткерә тырышабыз. Бу эшне бергәләп, зинһар, дөрес итеп эшлик, дибез. Төп фикеребез әнә шул. Хисап, квота сорамыйбыз. Санда түгел, сыйфатта эш.

:: Бүгенге балалар берләшергә ризамы?

– Төрлесе бар. Әйтик, аниме фестивале оештырабыз. Аның белән кызыксынган бик күп оешмалар бар. Меңләгән бала бит бу. Сәхнәдән сөйли башлагач, гаҗәпләнәләр. Алар бу хакта качып-посып сөйләшкән бит. Үзләре белән бер дулкында булганны сизгәч, тартыла башлыйлар. Киберспорт белән кызыксынучылар бик күп. Барысы да эчтәлеккә, аны җайга салган командадан тора. Кызык икән, тартылачаклар. Әлбәттә, бүгенге яшьләр икенче төрле. Алар шәхси уңышы, лидерлыкны өстен куя. Иҗтимагый эшкә җәлеп итү авыррак. Җаен табарга кирәк. Кызык булса, командага да кушылалар.

> Кызганыч, соңгы елларда интернет һәм социаль челтәрләр аша уңышның мәгънәсен башкача аңлатып сендерделәр. Яшьләрнең бар хыялы «Макдоналдс»та ашау, чит илгә китү булды. Бу бит – үз-үзебезне яратмау, мескенлек. Ничек котылырга? Үзебезгә мескен булмаска, үрнәк булырга, үзебезнеке белән горурланырга өйрәтергә кирәк.

:: Укытучыга да, остазга да актив дип саналган, ике әйттермәгән бала белән эшләү җиңелрәк. Әмма андыйлар күпчелек түгел. Читтә йөргән, игътибар җитмәгәннәрен ничек җәлеп итәргә?

– Алар янына барырга, алар йөргән сукмаклардан атларга кирәк. Без алар белән янәча аралашырга тиеш. Традицион кыйммәтләрне алар белән бер телдә сөйләшеп, аңлаешлы юл белән сеңдерергә тиеш. Әйтик, шул ук киберспорт. Әлбәттә, компьютер алдында сәгатьләр буе утыру зыянлы. Ә чамасын белсәң, була. Дулкын бар икән, аңа каршы барырга кирәкми. Йә башкасын эзләп табасың, йә аны дөрес юнәлешкә борасың. Чараларны мәктәптә генә түгел, урамда, ачык һавада оештыру нияте бар.

:: Яңа хәрәкәт илкүләм оешма булгач, бертөрле балалар килеп чыкмасмы? Әйтик, республикада Татарстанның төбәк һәм милли үзенчәлекләренә игътибар биреләчәкме?

– Биреләчәк. Бу оешмада 12 юнәлеш бар. Без федераль үзәк белән киңәшләшеп 13нчесен – «Туган тел, милли мәдәният һәм гореф-гадәтләр» дигәнен өстәдек. Оешманың 10 кагыйдә-принцибы бар. 11нчесен тәкъдим иттек һәм үзебезгә керттек. «Берлек – төрле булуда» дип атала ул. Без төрле – милләтләр, телләр төрле. Көчебез әнә шул төрлелектән барлыкка килә дә инде. Шуңа күрә аны Татарстанда үтәли кагыйдә-принцип итеп кулланачакбыз.

:: Бу бит – бөтен Россиягә ярарлык кагыйдә.

– Башкалар да куллансын. Мин бөтен Россия өчен җавап бирә алмыйм. Безнең бурыч – бу эшне Татарстанда дуслык һәм татулык белән алып бару. Бүленеп түгел, ә төрле булганнарны берләштереп. Үз тамырларыңны белергә, аның көчен тоярга, шуңа таянып, киләчәккә атларга. «Сәләт»тә үскәч, мин бу кагыйдәдән тайпылмаячакмын.

:: Бу эшнең нәтиҗәсен саннар белән үлчәп булмый һәм тиз генә күренмәс тә. Мондый оешма төзергә соңга калмадыкмы?

– Минемчә, соңардык. Әмма, шөкер, соңгы елларда йоклап утырмадык. Республикада төрле оешмалар һәм хәрәкәтләр бар. Буыннар алмашынып тора, әле остаз булырлык өлкән кешеләребез исән-сау. Безнең кебек 40–50 яшьлекләрне «чик сакчылары» дип атыйм. Бер яктан, заманча технологияләрне куллана беләбез. Икенче яктан, безгә элеккеге тәрбия дә эләкте. Ә яңа буынга аларда бердәмлек, командалык сыйфатын тәрбияләү, туган иленә, ана теленә, хезмәткә карата хөрмәт хисләрен уята торган яңа оешма кирәк.

Татарстан Рәисе белән сөйләшкәндә ул болай диде: әлеге хәрәкәтнең нәтиҗәсен 10 елдан күрә башлыйбыз. Һәр елга планыбыз бар. Быел, мәсәлән, һәр мәктәптә бу оешманың клублары оештырылырга тиеш. 1500–1600 чамасы клуб турында сүз бара. Һәрберсенә үзләре теләп берничә бала кушылса, шул чараларда катнашса, минемчә, бик яхшы нәтиҗә булачак. 2000нән артык остаз булырга тиеш. Быел хәрәкәт өчен 250 әйдаман әзерлибез, 16 смена оештыру нияте бар. Иң мөһиме – шул якка юл тоту. Акрын гына, дөрес юлда булу. Алда эш күп әле. Камиллекнең чиге юк.

Әңгәмәдәш – Илнар ХӨСНУЛЛИН

Эльвира ВӘЛИЕВА

БИРГӘННЕ АЛАСЫ

pixabay.com

Илдә яшәүче һәр ике кешенең берсе хезмәт хакыннан, керемнәрдән тотылып калган акчаны кире кайтармый. Халык арасында үткәрелгән сораштыру нәтиҗәләре бу. Югыйсә бүген спорт белән шөгыльләнгән өчен дә салым чигерүе каралган. Ә менә социаль ипотека буенча фатир алучыларга сабыр итәргә туры киләчәк. Акчаны кире кайтару юллары һәм салым өлкәсендәге соңгы яңалыклар турында «ВТ» хәбәрчесе белеште.

Интернетта финанс хезмәтләр тәкъдим итүче оешмаларның берсе үткәргән сораштырудан күренгәнчә, илдә яшәүчеләрнең 54 проценты салым чигерүен (вычет) бер тапкыр да рәсмиләштереп карамаган. Шул ук вакытта респондентларның 65 проценты түләнгән салым акчасының бер өлешен кире кайтару мөмкинлеге турында хәбәрдар булуын әйткән. Халыктан: «Ник салым чигерүен алмыйсыз?» – дип тә сораганнар. Баксаң, салым оешмаларын читләтеп кенә узучыларның һәр икенчесе диярлек (54 процент) документ эше артык катлаулы дип саный. Әнә шул куркыта да. Халыкның 17 проценты акча килгәнне, ә Салым кодексы нигезендә бу эш өч айга кадәр сузылырга мөмкин, озын-озаклап көтәргә яратмый. «Вычет» алмауга бәйле тагын бер сәбәп – илдә яшәүчеләрнең 13 процентының, гомумән дә, рәсми эш урыны юк икән.

Россиялеләрнең өчтән бере милек өчен салым чигерүен кайтара. Түләүле белем алу һәм табибларга мөрәҗәгать иткән өчен дә «вычет» рәсмиләштерүчеләр байтак. Халыкның күпчелеге, тәгаен әйтсәк, 54 проценты әлеге акчаны бурычларын түләүгә тотуын әйткән. Салым федераль хезмәтенең Татарстан буенча идарәсеннән алынган мәгълүматларга караганда, былтыр республикада яшәүчеләр 14,3 миллиард сумлык «вычет» алган.

Салым чигерүен алмауга еш кына белмәү түгел, ә белергә теләмәү сәбәпче, ди Татарстан буенча 6 нчы номерлы районара салым инспекциясенең баш дәүләт салым инспекторы Рәмзия Мөхетдинова.

– Хезмәт хакыннан, керемнәрдән тотылып калган акчаның бер өлешен салым чигерүе буларак кире кайтарырга мөмкин. «Вычет» берничә төргә бүленә. Арада иң еш кулланыла торганы **МИЛЕККӘ САЛЫМ ЧИГЕРҮЕ**дер, мөгаен. Милек бәясенең ике миллион сумыннан «вычет» кайтарып була. Ягъни кеше милек өчен түләгән акчаның 260 мең сумын кире кайтара ала. Салым чигерүе еллык хезмәт хакыннан тотып калынган салым күләмендә түләнә. Калган сумма да янмый, ул киләсе елларга чигерелә. Милек «вычет»ына тиешле сумманы бер объекттан кайтарып бетермәсәң, аны икенчесеннән алырга да була. Әмма бу 2014 елның 1 гыйнварыннан соң тораклы булучыларга гына кагыла. Милекне моңа кадәр үк сатып алгансыз икән, сез салым чигерүенә гомер эчендә бер мәртәбә генә дәгъва кыла аласыз, – ди салым инспекциясе белгече.

СОЦИАЛЬ «ВЫЧЕТ» түләп дәваланучы, түләп укучыларга каралган. Кеше үзен, балигъ булмаган баласын, ирен яки хатынын, әти-әнисен дәвалау өчен тотылган сумма, кирәкле дару һәм препаратлар сатып алу өчен сарыф ителгән акчадан салым чигерүенә дәгъва кыла ала.

– Укыганга акчаны кире кайтару өчен эшләмәүче студент көндезге бүлектә, эшләүчесе кичке яки читтән торып уку бүлегендә белем алырга тиеш, – ди Рәмзия Мөхетдинова. – Көндезге бүлектә укучы баласы өчен салым чигерүен әти-әнисе кайтара. Түләп укыган өчен кайтарылган «вычет» күләме бер балага 50 мең сумнан да артмый. Баланың укуына түләү өчен ана капиталы акчасы тотылган булса, салым чигерүе кайтарылмый. Сүз уңаеннан, музыка мәктәбе, автомәктәптә укыган өчен дә «вычет» кайтарырга мөмкин.

СТАНДАРТ САЛЫМ ЧИГЕРҮЛӘРЕн балигъ булмаган балалары яисә көндезге бүлектә белем алучы 24 яшькә кадәрге балалары булган ата-аналар, опекуннар, попечительләр кайтара ала. Ул эш урыныннан бирелә. Моның өчен бухгалтериягә баланың туу турында таныклыгын тапшырып, гариза язарга кирәк. Әгәр бу акчаны эш урыныннан бирмәсәләр, кеше аны декларация нигезендә салым органы аша кайтара ала. Ел дәвамында керем 350 мең сумнан артса, стандарт «вычет» бирелми.

Былтыр салым чигерүләренә бәйле яңалыклар да гамәлгә кергән.

– Моңарчы әти-әниләр көндезге бүлектә белем алучы 18 яшькә кадәрге баланы дәвалауга киткән чыгымнардан гына салым чигерүе алырга хокуклы иде. 2022 елда әлеге чикне 24 яшькә кадәр күтәрделәр. Хәзер төрле фитнес-клубларда, бассейн, спорт залларында шөгыльләнгән өчен түләгән акчадан да «вычет» кайтарып була. Әмма бу министрлык тарафыннан расланган исемлеккә кергән спорт, сәламәтләндерү оешмаларына гына кагыла. Закон былтыр гамәлгә керде. Шуңа күрә 2022 елда сатып алынган юлламалар өчен салым «вычет»ын түүге тапкыр быел кайтарып булачак, – ди баш дәүләт салым инспекторы.

Узган елдан башлап социаль ипотека буенча фатир ачкычы алучыларга да сабыр итәргә туры киләчәк. Моңарчы ташламалы дәүләт программасы нигезендә тораклы булучылар, гади ипотека программасыннан файдаланучылар белән берррәттән, ел саен фатир өчен түләнгән акчаның бер өлешен салым чигерүе рәвешендә кайтарып барды. Бу эш кабул итү – тапшыру акты нигезендә башкарылды. Моннан ары социаль ипотека буенча алган фатирга милек «вычет»ы рәсмиләштерү өчен, аның акчасын тулысынча түләп бетереп, кулга Салым түләүчеләрнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә алганны көтәргә туры киләчәк (яңалык моңа кадәр фатир алучыларга кагылмый. – **Ред.**). Соңгы арада гына Казанда РКБ табибларына, укытучыларга социаль ипотека программасы буенча ачкыч тапшырдылар. Димәк, аларга сабыр итәсе була. Шунысын да искәртик: түләнгән акча югалмый. Аны соңыннан хезмәт хакыннан тотылган салым күләмендә акрынлап кайтарып булачак. Әлеге яңалык өлешләп төзү буенча килешү төзүчеләргә дә кагыла.

Яшел Үзәндә яшәүче бухгалтер Гөлназ Сиражиева салым өлкәсендәге «белмәмеш»ләргә салым чигерүләрен кайтару өчен 3-НДФЛ тутыру белән шөгыльләнә.

– Соңгы бер ел – ел ярымда «вычет» рәсмиләштерергә ярдәм итеп мөрәҗәгать итүчеләр саны кимеде. Чөнки моны мөстәкыйль рәвештә салым түләүченең шәхси кабинеты аша да бик җиңел эшләп була. Бу хакта белеп кенә бетермиләр яки ялкауланалар. 3-НДФЛны 500 сумга тутырам. Салым инспекциясенә бармыйча, документларны шәхси кабинет аша гына җибәрергә киңәш итәм. Чөнки интернет аша эш итсәң, салым чигерүе күпкә тизрәк килә. Хәзер моның өчен гадәттә бер айга кадәр вакыт та җитә, – ди Гөлназ Сиражиева.

САЛЫМ ЧИГЕРҮЛӘРЕ БУЕНЧА ФИЗИК ЗАТЛАРГА КАЙТАРЫЛГАН АКЧА



«Акча туздырыр чак түгел»

Акча дигәннән, бүген акча янчыгы тирәсендә болытлар куера. Доллар үсә, рубль түбән тәгәри: безне ни көтә? Мондый шартларда җыйган акчаны нишләтергә? Бу хакта белгечләрдән сорадык.

Фәнис ХӨСӘЕНОВ, Татарстан Иҗтимагый палатасының финанс мәсьәләләре буенча белгече:

– Әлбәттә, рубльнең очсызлануы бәяләр үсешенә китерә. Әмма әлеге үсеш тә төрле була ала. Бүген без рубльнең девальвациясе (башка валюталар белән чагыштырганда илкүләм валютаның курсы түбән төшү) аркасында бәяләр бик нык үсүен күрмибез. Моңа ике сәбәп бар. Беренчедән, соңгы бер елда илдә җитәрлек күләмдә импорт сатып алынды. Икенчедән, кулланучылар арасында сорау моңарчы ничек түбән дәрәҗәдә булса, бу хәзер дә шулай. Искә төшерик: узган елның сентябрендә илдә өлешчә мобилизация игълан ителгәннән соң, халык акчаны артык әрәм-шәрәм итмичә, аны җыеп баруга кереште. Без бүген дә әнә шул хәлдән чыкмаган әле. Халык мая туплавын дәвам итә. Шунысы да бар: кесәдәге акчаны туздыра башлау өчен иртәгәге көнгә ышаныч кирәк. Кызганыч, бүгенге вазгыять мондый мөмкинлек бирми. Шуңа күрә ил күләмендә кредит алучылар саны да кимеде әнә. Әйе, девальвация турыдан-туры тәэсир итә торган товарларның бер төркеме бар. Ул – автомобиль базары. Сер түгел, юллардагы машиналарның күпчелеге – чит илнеке. Рубльгә бәйле үзгәрешләр шунда ук автомобиль бәяләрендә чагыла. Шуңа күрә якын арада машина сатып алырга җыенасыз һәм кулда акчагыз бар икән, моны эшләргә кирәк. Гомуми күзлектән чыгып шуны гына әйтә алам: бүген халык акча туздырырга ашкынып тормый.

Сирин ЗАРИПОВ, финанс киңәшче:

– Җыйган акчасын долларда саклаучыларга валюта базарына бәйле соңгы үзгәрешләр берничек тә тәэсир итмәячәк. Маягыз рубльдә икән, кызганыч, ул долларга карата күпмедер дәрәҗәдә үз кыйммәтен югалтачак. Шуңа күрә җыйган акчаны берничә төрле валютада, мәсәлән, долларда һәм рубльдә сакларга киңәш итәм. Акча саклауның алтын кагыйдәсе – диверсификация (аны төрле юнәлешләрдә тоту) турында да онытырга ярамый. Форсаттан файдаланып, кесәдәге долларларын алмаштырып калырга теләүчеләр моннан әллә ни отмаячак. Һәр нәрсәдәге кебек үк, бу эштә тә белгеч булу кирәк. Гомумән, зур суммада долларлы мая туплау дөрес түгел дип саныйм. Ничек кенә булмасын, акчаны инфляция ашый. Аны керем китерүче актив буларак саклау отышлырак.

! Кайтарырга мөмкин булган акча якын арада үк тагын да артып китмәгәе әле. Россия Дәүләт Думасы депутатлары 24 яшькә кадәр балаларны укытуга киткән чыгымнардан салым чигерүен 50 мең сумнан – 110 мең сумга, ә дәвалану, медицина препаратлары сатып алу һәм үзеңә белем арттыруга бәйле «вычет»ны 120 мең сумнан 150 мең сумга кадәр арттыруга бәйле закон проекты әзерләде. Балага белем биргәндә 50 мең сум судагы тамчы кебек кенә, билгеле. Тик акчаның артыгы юк. Өстәп булса да әйтик, әлеге төр социаль салым чигерүе 2003 елда 25 мең сумнан – 38 мең сумга, 2006 елда 38 мең сумнан 50 мең сумга кадәр арттырылган булган инде.

Зөһрә
САДЫЙКОВА

СЫЕР ДА ТӘМЛЕНЕ ЯРАТА



Кешедән аермалы буларак, терлекләр авырткан урынын күрсәтә алмый. Димәк, бар өмете хуҗасының игътибарында. Ә терлеге авырып китсә, авыл кешесенең тынычлыгы бетә. Газета укучыларыбызның мәшәкате азрак булсын дип, алардан килгән сорауларны Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе җитәкчесе урынбасары Илдар НУГУМАНОВка бирдек.

?Малларның колакларына чип куя башладылар, нәрсә өчен эшлиләр аларны? Сыерның туган көненә кадәр сорау кирәкме икән?

Фәнзил КАДЫРОВ

– 2023 елның 1 сентябреннән Россиядә яңа закон гамәлгә кертеләчәк. Аның буенча эре мөгезле терлек, кәҗә, сарык, дуңгыз, ат, кош-корт һәм бал кортлары барысы да исәптә булырга тиеш. Шәхси хуҗалыкларда бу эшләр быелдан башланып китте. Исәп алып барганда колакларына куела торган тамгалар өчен Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов акча бүлеп бирде. Киләчәктә аларны һәр хуҗалык үзенә алырга тиеш булачак. Компьютерда терлекләрнең барлык мәгълүматлары язылачак. Хәзерге вакытта шәхси хуҗалыклардагы терлекләрнең 45 проценты идентификацияләнде. 1,5 ай эчендә барысын да исәпкә алып бетерергә тырышабыз. Туган көннәре генә түгел, һәр малның нәсел-нәсәбе, каян кайтуы, күпме сөт бирүе, прививкалар – барлык мәгълүмат тупланачак.

?Терлекләрнең колакларына куйган биркалар сынып, бер-ике көн эчендә колагыннан килеп тә төште. Бер сыерныкы бөтенләй колагы белән ертылып килеп чыкты. Нилектән шулай булды икән? Хәзер аны кабат куйдырырга кирәк булачакмы? Мондый очракта нишләргә?

Зәлифә МОСТАФИНА. Азнакай районы Беренче Май авылы

– Андый очракта участок мал табибына хәбәр итәргә кирәк. Терлекләрнең колакларына үз номерлары сугылган биркаларны кабат бирәчәкләр. Ләкин бу очракта инде тамга өчен хуҗаларның үзләренә түләргә туры киләчәк. Без терлекләрнең бер колагына түгәрәк формада электрон тамга, икенчесенә алка куябыз. Кызганыч, сыну очраклары бар. Ләкин алар үзләреннән-үзләре генә килеп төшми. Маллар бер-берсе белән сөзешкәндә, каядыр кысылып калганда алкасына зыян килергә мөмкин.

?Соңгы елларда прививка бик күп ясыйлар. Аларны истә дә калдырып бетереп булмый. Сыерларның буаз кала алмавын яки авыру бозау табуын шуңа бәйләп аңлатучылар да бар. Чынлап та, соңгы елларда андый хәлләр ешайды. Ни өчен соңгы елларда прививкаларга игътибар артты, һәм алар терлекләргә нинди зыян салырга мөмкин?

Таһир ӘҮХӘДИЕВ. Чүпрәле районы

– Прививкалар сыерның «капланмавына» яки бозаулый алмыйча азаплануына берничек тә йогынты ясамый. Аның сәбәпләре башкада булырга мөмкин. Ташлатканнан соң сыерны бик нык ашатсалар, бозау зур үсә һәм бозаулавы да авыр була. Икенчедән, гадәттә сыерларның бозаулый торган вакыты декабрь – март айлары дип санала. Бу чорда маллар күбесенчә абзарда тора, аз хәрәкәтләнә, витаминнар да җитеп бетми. Прививкаларга килгәндә, соңгы елларда без нодуляр дерматитка каршы прививканы өстәдек. Ул елына ике тапкыр ясала. Вакцинадан башка булмый, чөнки ул – куркыныч авыру. Тагын бер прививка котыру авыруына каршы ясала. Соңгы елларда республикада бу авыру азайса да, куркыныч бар, шуңа күрә саклану комачауламый. Моннан тыш, Себер түләмәсенә прививка соңгы 8–9 елда ике тапкыр ясала башлады. Элек аны бер тапкыр гына ясыйлар иде. Нәтиҗәсе дә бар. Моңа кадәр ике-өч елга бер тапкыр чыккалап торган авыру хәзер күренми. Шуңа күрә, малларның прививканың зыяны бар, дип әйтү дөрес булмас. Ул әллә нигә бер тапкыр аллергия гына бирергә мөмкин. Мондый хәл күпчелек очракларда яшь бозауларда күзәтелә. Көчле аллергия үлемгә дә китерергә мөмкин.

?Прививка ясатканнан соң терлекләрне күпме вакыт узгач суярга ярый?

Лилия КУПАЕВА. Әлмәт районы Бишмунча авылы

– Һәр прививканың үз кагыйдәсе бар. Шуңа күрә бу мәгълүматны прививка ясарга килгән табибтан белешеп калырга тырышыгыз. Әйтик, котыру чиренә каршы ясалган прививкадан соң малны теләсә кайсы вакытта чалырга мөмкин. Ә инде Себер түләмәсенә каршы ясалганда, ун көн узмыйча, малны суярга ярамый. Мастит белән авырган сыерны антибиотик белән дәваларга туры килгәндә, шулай ук билгеле бер аралыкта суярга ярамый.

?Сыер сөтенең майлылыгы нәрсәгә бәйле?

Гөлчирә НИЗАМОВА. Теләче районы

– Сыер сөтенең майлылыгына күп нәрсә бәйле. Беренчедән, дөрес ашату. Микроэлементлар, клетчатка (печән, сенаж) җитеп бетмәсә дә сөтнең майлылыгы төшеп китәргә мөмкин. Кайберәүләр, сыер мул сөт бирсен өчен, күпләп фураж ашата башлый. Арпа, бодай, кукуруз шикәргә бай. Ул кирәгеннән арткан очракта, сыерның ашказаны кислотасы күтәрелеп китә һәм сөтнең майлылыгы кинәт төшә башлый. Жом, чүпрә, борчак, соя белән күп аксым кереп, алкалоз дигән авыру китереп чыгарырга мөмкин. Шуңа күрә һәр нәрсәне – фуражны да, аксымны да чамасын белеп кенә бирергә кирәк.

Зөлфия Хәлиуллина

?Узган ел районнан УЗИ ясаучыны чакырдык. Ул карагач, сыер буаз түгел, дип китте. Тик берничә көннән суйгач, йон чыгып, үсеп беткән бозавы барлыгы ачыкланды. Бик кызганыч. Яки акча түләп чакырткан белгечләр, буаз сыерны, кысыр, дип китә. Ялгышлык нилектән килеп чыга? УЗИ аппаратлары иске, начармы, әллә мал табибы тәҗрибәсезме? Хуҗалыкларга ничек алданмаска?

Гөлүсә ГАБДРАХМАНОВА. Актаныш

– Кызганычка, мондый очраклар да була. Монда гаеп аппараттадыр дип уйламыйм. Үзем дә 10 елдан артык авыл хуҗалыгында эшләдем. Элек, УЗИ аппаратлары булмаганда, без сыерның буаз булу-булмавын кул белән карап билгели идек. Ул вакытта иң яхшысы – сыер капланганнан соң 2–3 ай узгач карау, чөнки бу вакытта нәтиҗә шунда ук сизелә. Буазлылыкның 4,5–5,5 аенда бозауны сизү бик авыр, чөнки ул бик аста ята. Кул белән генә тотып карап булмый. Бәлки белгеч нәкъ шул вакытта карагандыр? Алай да булуы мөмкин. Ул очракта кул белән аналыкның кан тамырларын тотып карый идек. Аналык аска төшеп киткән булса, бозауның 4–6 айда булуын чамаларга була. 7 айларда инде бозау уң яктан төртеп караганда ук сизелә. Авыл, район җирлекләрендә яхшы, тәҗрибәле белгечләр турында халык ишетеп, белеп тора. Шуңа күрә оста белгечләргә мөрәҗәгать итәргә тырышырга кирәк.

?Сыер ничә айлык буаз чакта УЗИ ясату зарарлы икән?

Чулпан ҺАДИЕВА. Кукмара районы Бакчасарай авылы

– Сыерны каплатканнан соң, бер ай узганчы УЗИ ясарга киңәш ителми. Эре хуҗалыкларда гадәттә бер ай һәм өч ай узгач карыйлар. Шәхси хуҗалыкларда 2,5–3,5 айда карату яхшы. Әйткәнемчә, бу – карау өчен иң яхшы вакыт.

?Яңа туган бөтен бозауга да бер төрле игътибар күрсәтәбез. Бер үк ризык бирәбез. Тик кайберләренең эче китеп җәфалана. Нилектән шулай була һәм ничек дәваларга икән?

Алсу ГАРӘФИЕВА. Азнакай

– Яшь бозауларның эче китүенең төп ике сәбәбе бар. Аның беренчесе – угыз сөтен дөрес эчертмәү. Сыер бозаулагач, беренче савым алдыннан, җиленнәрен бик яхшы итеп юарга кирәк. Аннан соң бераз гына аерым савытка савып алу яхшы, чөнки монда бөтен микроблар җыела. Савыт төбендә мастит эремчеге булмавына инангач кына угызны бозауга савып эчертергә яки әнисенә китереп имезергә була. Угызны бозау туганнан соң бер сәгать эчендә имезү әйбәт. Мондый бозау сәламәт була, эч китү белән дә артык проблемалар булмаска тиеш. Тик һәр нәрсәдә чисталык булырга тиеш. Икенчедән, яшь бозауга сөтне 37,5–39 градуска кадәр җылытып эчертергә кирәк. Салкынрак яки кайнаррак сөт шулай ук бозауның ашказанына килешми, эчен җибәрергә мөмкин.

?Еш кына малларның эчләре тау кадәрле булып кабара. Аның сәбәпләре нидә һәм дәвалау ысуллары нинди икән?

ИЛҺАМИЯ апагыз. Мөслим районы

– Бу малның ашаган ризыгына бәйле. Эч кабару гадәттә көтүгә чыкканда еш күзәтелә. Зур терлекләргә люцерна, клевер биргән очракта шулай булырга мөмкин. Яшь бозауларның эче сөтне шулай ук дөрес эчертмәгән очракта кабарырга мөмкин. Кинәт кабарса, мал табибын чакырырга кирәк. Ул килеп җиткәнче, сул яктан кабарган очракта, энә белән аркылы тишеп, һавасын чыгарырга мөмкин.

?Атларга паразитларга каршы укол кадату яхшыракмы, әллә дару бирүме? Аларны сезонга ничә тапкыр бирү яхшырак? Альбенны фураж белән катыштырып бирсәң яхшыракмы, әллә су белән чылатып бирү уңышлыракмы?

Илшат ГАРИФУЛЛИН. Кайбыч районы

– Даруны елына ике тапкыр бирергә кирәк. Башкача булганда, паразитлар азып, атны үтерергә дә мөмкин. Без гомер буе даруларны фураж белән бутап бирдек.

17 апрель | Душәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
07.00, 18.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.00 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ 2». Телесериал 16+
10.00, 23.00 «ТАИНСТВЕННАЯ СТРАСТЬ». Телесериал 12+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
11.30, 16.30 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.10 «ӨЧ ДУС». Телесериал 16+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә». «Акыл батл» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
18.00 «Таяну ноктасы» 16+
19.30 Хоккей. Кубок Гагарина. Финал. Прямая трансляция 0+
22.00 «Вызов 112» 16+
00.00 «Каравай». Фольклор татар-мишар 6+
00.25 «Таяну ноктасы» 16+
00.50 «Кәмит Җәвит» 16+
01.45 «Рыцари вечности» 16+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 16+
04.45 «Җырлыйк әле!» 12+
05.35 «Онъта алмыйм...» Ретро-концерт 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 23.10, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Туган җир» 12+
12.05, 18.20, 21.25 «АЛМАШ». Телесериал 16+
15.25, 20.30 «Заман көзгесе» 6+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
17.30 «Яшьләр тукталышы» 6+
19.15 «Музыкаль мәйдан» 16+
19.30 «Калеб» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
22.20, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
00.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
00.40 «Үткәннәр сагындыра» 12+
02.50 «Караоке татарча» 12+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
19.50 Премьера. «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. «ЗА ПОЛЧАСА ДО ВЕСНЫ». Многосерийный фильм (S) 12+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Антропология» 16+
00.25 ПОДКАСТ.ЛАБ «Пусть не говорят, пусть читают» 16+
01.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Собрались с мыслями» 16+
01.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Космические истории» 16+
02.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Триггеры» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Креативные индустрии» 16+
03.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Неформат» 16+
04.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Письма» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Елена Аросьева, Александр Константинов, Иван Шибанов, Фёдор Шувалов, Олег Алмазов. «ЛЮБОВЬ ПРЕОДОЛЕЕТ ВСЁ» 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 Детективный телесериал «ДУЭТ ПО ПРАВУ» 12+
03.55 Вячеслав Разбегаев, Кирилл Плетнёв, Наталия Быстрова, Анна Гарнова, Андрей Арзяев, Дмитрий Ермак. «ПЫЛЬНАЯ РАБОТА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 Профилактика на канале с 6.00 до 10.00
10.00, 12.55, 14.55, 16.40 Новости
10.05, 12.35, 00.35 Специальный репортаж 12+
10.25 Спортивный дайджест 0+
11.25 Смешанные единоборства. UFC. Тони Ферпосон против Джастина Гейтжи. Трансляция из США 16+
13.00 «Есть тема!» Прямой эфир
14.25 «Лучшие из лучших» 12+
15.00 «География спорта. Саратов» 12+
15.30 Футбол. МИР Российская Премьер-Лига. Обзор тура 0+
16.45 «Громко». Прямой эфир
17.55 Плавание. Чемпионат России. Прямая трансляция из Казани
19.00 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. Кубок Гагарина. Прямая трансляция
21.45 Футбол. Чемпионат Италии. «Фиорентина» – «Аталанта». Прямая трансляция
23.45 Все на Матч! Прямой эфир
00.55 Баскетбол. Единая лига ВТБ. 1/2 финала. ЦСКА – «Локомотив-Кубань» (Краснодар) 0+
02.55 Новости 0+
03.00 Футбол. Чемпионат Германии. «Вольфсбург» – «Байер» 0+
05.00 Плавание. Чемпионат России. Трансляция из Казани 0+

НТВ

04.45 Павел Делонг, Георгий Дронов в сериале «ПЛЯЖ. ЖАРКИЙ СЕЗОН» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Остросюжетный детектив «НЕВСКИЙ. РАСПЛАТА ЗА СПРАВЕДЛИВОСТЬ» (S) 16+
22.10, 00.00 Остросюжетный детектив «МЕТОД МИХАЙЛОВА» (S) 16+
00.35 Остросюжетный сериал «УГРО» (S) 16+
03.50 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.40 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.05 «Давай разведёмся!» 16+
09.05 «Тест на отцовство» 16+
11.15 «Понять. Простить» 16+
12.25 «Порча». «Другая неправда» 16+
12.55 «Знахарка» 16+
13.30 «Верну любимого» 16+
14.05 «Голоса ушедших душ» 16+
14.35 «ПРЯНЫЙ ВКУС ЛЮБВИ» 16+
19.00 «ДАЛЁКАЯ И БЛИЗКАЯ» 16+
22.05 «Забота о важном» 16+
22.10 «ДАЛЁКАЯ И БЛИЗКАЯ» 16+
23.15 «УЛЫБКА ПЕРЕСМЕШНИКА». 1-я – 4-я серия 16+
03.35 «Порча» 16+
04.00 «Знахарка» 16+
04.25 «Верну любимого» 16+
04.55 «Голоса ушедших душ» 16+
05.20 «6 кадров» 16+
05.35 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.00 «ПИРОЖКИ С КАРТОШКОЙ» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20 «НЕПОДДАЮЩИЕСЯ» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20, 15.05 «СМЕРТЬ ШПИОНАМ!». 1-я – 4-я серии 16+
15.00 Военные новости. 16+
18.20 «Специальный репортаж» 16+
18.55 «Освобождая Родину. Битва за Север. Провал «Серебристой лисы». Документальный сериал. 1-я серия 16+
19.40 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Документальный сериал 12+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.25 «СЕМНАДЦАТЬ МГНОВЕНИЙ ВЕСНЫ». 1-я – 3-я серии 12+
03.00 «Москва – фронту». Документальный сериал 16+
03.25 «СМЕРТЬ ШПИОНАМ!» 1-я и 2-я серии 16+

18 апрель | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
07.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ 2». Телесериал 16+
10.00, 23.30 «ТАИНСТВЕННАЯ СТРАСТЬ». Телесериал 12+
11.00 «Азбука долголетия» 16+
11.15 «Память сердца» 16+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.40 «ӨЧ ДУС». Телесериал 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 16+
14.00 «Путь» 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» 0+
16.00 «Ватандашлар» 16+
18.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.30 Татарстан хәбәрләре 16+
21.00, 22.10 «Трибуна «Нового Века» 16+
22.40 «Өч дус». Телесериал 16+
00.20 «Видеоспорт» 16+
00.45 «Соотечественники». Пастернак на фоне Чистополя 16+
01.10 «Каравай». Промыслы 6+
01.35 «Онъта алмыйм...» Ретро-концерт 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 23.10 «Җырлыйк әле!» 12+
09.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
10.30, 20.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Нәсыйхәт» 16+
12.05, 18.20, 21.25 «АЛМАШ». Телесериал 16+
15.25, 20.00 «Таяну ноктасы» 16+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00, 19.15 «Музыкаль мәйдан» 16+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
01.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
19.50 Премьера. «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. «ЗА ПОЛЧАСА ДО ВЕСНЫ». Многосерийный фильм (S) 12+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Жизнь замечательных» 16+
00.25 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+
01.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Песняры» моей жизни» 16+
01.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Психика» 16+
02.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Все хотят летать» 16+
03.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Обязательно к прочтению» 16+
04.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Антропология» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Елена Аросьева, Александр Константинов, Иван Шибанов, Фёдор Шувалов, Олег Алмазов. «ЛЮБОВЬ ПРЕОДОЛЕЕТ ВСЁ» 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 Детективный телесериал «ДУЭТ ПО ПРАВУ» 12+
03.55 Вячеслав Разбегаев, Кирилл Плетнёв, Наталия Быстрова, Анна Гарнова, Андрей Арзяев, Дмитрий Ермак. «ПЫЛЬНАЯ РАБОТА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 14.25 «Лучшие из лучших» 12+
06.30 «География спорта. Саратов» 12+
07.00, 10.00, 12.55, 14.55 Новости
07.05, 15.30, 21.25, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 12.35 Специальный репортаж 12+
10.25 Еврофутбол. Обзор 0+
11.25 Бокс. Bare Knuckle FC. Джо Риггз против Мелвина Гилларда. Трансляция из США 16+
13.00 «Есть тема!» Прямой эфир
15.00 «Ты в бане!» 12+
16.00 Профессиональный бокс. Марк Петровский против Владислава Вишева. Прямая трансляция из Уфы
17.55 Плавание. Чемпионат России. Прямая трансляция из Казани
19.25 Баскетбол. Единая лига ВТБ. 1/2 финала. УНИКС (Казань) – «Зенит» (Санкт-Петербург). Прямая трансляция
21.40 Футбол. Лига чемпионов. 1/4 финала. «Челси» (Англия) – «Реал» (Мадрид, Испания). Прямая трансляция
00.55 Футбол. Лига чемпионов. 1/4 финала. «Наполи» (Италия) – «Милан» (Италия) 0+
02.55 Новости 0+
03.00 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Мужчины. 1/2 финала 0+
05.00 Плавание. Чемпионат России. Трансляция из Казани 0+

НТВ

04.45 Сериал «ПЛЯЖ. ЖАРКИЙ СЕЗОН» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Остросюжетный детектив «НЕВСКИЙ. РАСПЛАТА ЗА СПРАВЕДЛИВОСТЬ» (S) 16+
22.10, 00.00 Остросюжетный детектив «МЕТОД МИХАЙЛОВА» (S) 16+
00.35 Остросюжетный сериал «УГРО» (S) 16+
03.50 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.20 «Давай разведёмся!» 16+
09.20 «Тест на отцовство» 16+
10.35 «Забота о важном» 16+
10.40 «Тест на отцовство» 16+
11.35 «Понять. Простить» 16+
12.40 «Порча». «Основательный подход» 16+
13.10 «Знахарка» 16+
13.45 «Верну любимого» 16+
14.25 «Голоса ушедших душ» 16+
15.00 «УСПЕТЬ ВСЁ ИСПРАВИТЬ» 16+
19.00 «ВСЁ РАВНО ТЫ МОЯ» 16+
22.05 «Забота о важном» 16+
22.10 «ВСЁ РАВНО ТЫ МОЯ» 16+
23.15 «УЛЫБКА ПЕРЕСМЕШНИКА». 5-я – 8-я серия 16+
03.30 «Порча» 16+
03.55 «Знахарка» 16+
04.20 «Верну любимого» 16+
04.50 «Голоса ушедших душ» 16+
05.15 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.05 «СМЕРТЬ ШПИОНАМ!» 3-я и 4-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20 «ЗА ВИТРИНОЙ УНИВЕРМАГА» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20, 15.05 «СМЕРТЬ ШПИОНАМ!» 5-я – 8-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.20 «Специальный репортаж» 16+
18.55 «Освобождая Родину. Битва за Север. Провал «Серебристой лисы». Документальный сериал 2-я серия 16+
19.40 «Улика из прошлого» 16+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.25 «СЕМНАДЦАТЬ МГНОВЕНИЙ ВЕСНЫ». 4-я – 6-я серии 12+
03.30 «СМЕРТЬ ШПИОНАМ!». 5-я и 6-я серии 16+

КОНТРАКТ БУЕНЧА ХӘРБИ ХЕЗМӘТ

РФ ОБОРОНА МИНИСТРЛЫГЫ БЕЛӘН КОНТРАКТ ТӨЗЕГӘЧ, БЕР ТАПКЫР ТҮЛӘНЕЛӘ:
195 000 СУМ
Махсус хәрби операциядә катнашкан өчен өстәмә түләүләр каралган
ХӘРБИ КОМИССАРИАТКА МӨРӘҖӘГАТЬ ИТҮ ӨЧЕН: 8(843) 221-44-52

«КАРПАТКА» һәм «КАРНИКА»
токымлы 4әр рамлы умарталар сатам.
Бал корты личинкалары – 2–3 рам.
Бал икмәге – 1 рам.
+7 96 55 99 88 67
+7 96 25 61 60 93
Реклама

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

ЯЗГЫ СЫНАУ

АЛЛЕРГИЯ АЯКТАН ЕКМАСЫН ӨЧЕН НИ ЭШЛӘРГӘ?

Җир шарында яшәүчеләрнең 20 процентка якыны аллергиядән интегә. Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы белгечләре әйтүенчә, шуларның яртысыннан артыгы – сезонлы аллергия корбаны. Бар дөнья яшеллеккә күмелгән яз аенда аннан интегүчеләр саны бермә-бер арта. Сезонлы аллергия чорына ничек әзерләнергә? Бу чорда ничек тукланырга?

stock.adobe.com

Әлеге сораулар белән Казан шәһәренең Тимерьюлчылар сырхауханәсенең гомуми практика табибы Ләйсән ШӘЙХУЛЛИНАга мөрәҗәгать иттек.

:: Сезонлы аллергия ни сәбәпле пайда була?

– Үсемлек һәм агач серкәсенә, күгәрек гөмбә спорасына аллергия башлану фәнни телдә поллиноз дип атала. Бездә сезонлы аллергия чоры апрельдән октябрьгә кадәр – үсемлекләрнең чәчәк аткан мәлендә күзәтелә. Аңа олысы да, кечесе дә бер үк дәрәҗәдә бирешә. Соңгы елларда поллиноз яшәрә бара. Элегрәк ул, өлкәннәр белән беррәттән, алты яше тулган балалар арасында күбрәк очраган булса, хәзер бер яшьлек балага да сезонлы аллергия диагнозы куярга туры килә.

:: Поллиноз вакытында организмда нинди үзгәрешләр күзәтелә?

– Кеше берөзлексез төчкерергә тотына, борыны, күзе кычытудан интегә, күзеннән яшь ага, күз кабаклары шешеп чыга. Кешенең тыны кысылырга, ютәл башланырга да мөмкин. Сезонлы аллергия вакытында еш кына тән тиресе дә бозыла. Вакытында чарасын күрмәсәң, поллиноз бронхитка ук әверелә ала.

:: Аллергиянең билгеләре салкын тигәндә, вируслы инфекция эләктергәндә күзәтелә торганнары белән дә бик охшаш бит. Аларның берсен икенчесеннән ничек аерырга?

– Инфекцияле авырулардан аермалы буларак, аллергия вакытында температура күтәрелми, тән сызлау, авырту кебек билгеләр күзәтелми. Ә менә берөзлексез төчкерү, йөткерү, борыннан агу, күкрәк читлеге кысу, һава җитмәү, сулыш алу авырлашу, буылу, күз, борын кычыту, күз кабаклары шешү, тел ою, гадәттә, нәкъ менә аллергия вакытында пәйда була. Кайбер кеше күңел болгану, эч китүдән дә тилмерергә мөмкин.

:: Аллергиядән прививка ясаткан кеше сезонлы аллергияне җиңелрәк уздыра, диләр. Бу, дөрестән дә, шулаймы?

– Әйе, шулай. Иммунитетны күнектерү максатыннан, организмга махсус рәвештә чир китереп чыгаручы аллерген кертелә. Шул рәвешле сезонлы аллергия «котырган» чорны кеше, дөрестән дә, җиңелрәк кичерә. Шуңа күрә бу прививканы алдан – кыш көне ук ясатып куярга киңәш ителә.

:: Сезонлы аллергиядән интеккән кеше ничек тукланырга тиеш?

– Андый кешеләргә бу чорда бал ашаудан, составында төрле буяу, ясалма кушылмалар булган кәнфит, йогырт кебек тәм-томнардан баш тартырга киңәш ителә. Монда күп әйбер кешенең конкрет кайсы үсемлек серкәсенә аллергиясе булуга бәйле. Әйтик, каен агачына аллергиясе булган кешеләргә алма, шәфталу (персик) кебек төшле җиләк-җимеш, кишер, чикләвек ашарга ярамый. Әремне өнәмәүчеләргә ромашка, гәрчич, сельдерей, шәфталу һәм кайбер төр тәмләткечләрдән ерак торырга кирәк. Сезонлы аллергия котырган чорда майлы балык ашагыз. Ул аллергия билгеләрен киметергә ярдәм итәчәк. Имбир белән суган да шундый үзлеккә ия. Аш та файдалы. Ул сулыш юлларын аллергия аркасында җыелган лайладан чистарта.

Агачлар чәчәк аткан язгы чорда аллергиядән интегүчеләр түбәндәге кагыйдәләрне истә тотарга тиеш:

✓урамга булдыра алганча сирәгрәк чыгарга тырышыгыз. Бигрәк тә җилле көнне өйдә утырырга киңәш ителә;
✓табигатьтә ял итүләрне дә чикләп тору хәерле;
✓дөрес тукланырга тырышыгыз;
✓язгы аллергия чорында үләннәр белән дәвалануны да кичектереп торырга туры киләчәк. Ромашка, бал, каен бөресе һ.б. салып ясалган төнәтмәләр хәлне тагын да катлауландырачак кына;
✓борынны кайнатып суытылган җылымса су белән көненә 3–4 мәртәбә юдыру да файдалы;
✓даруларны фәкать табиб белән киңәшләшкәч кенә эчәргә ярый;
✓агачлар, үсемлекләр чәчәк аткан чорда аллергиясе башланган кешеләргә бүлмәләрне җилләтергә дә киңәш ителми. Хәзер һавадагы тузанны су ярдәмендә җыючы махсус җайланмалар бар. Бүлмәне җилләтеп булмаганда, шуннан файдаланырга мөмкин;
✓йорт тузанына аллергиясе булган кешеләргә, киресенчә, бүлмәләрне даими рәвештә җилләтеп, дымлы чүпрәк белән тузанны сөртеп торырга киңәш ителә.

Үзем сынадым

Иммунитетны ныгытабыз

Соңгы елларда иммунитетны ныгыта торган бер катнашма кулланабыз. Аллага шөкер, файдасы сизелә. Аны ясау өчен 300–350 грамм имбир тамыры, 150–200 грамм бал һәм 1–2 лимон кирәк. Имбир тамырын чистартып, зур булмаган кисәкләргә бүләбез. Лимонны өлешләргә кисеп, орлыкларын алабыз һәм икесен дә иттарткычтан чыгартабыз. Бал кушып, бик яхшылап болгатабыз. Шуны көнгә бер бал кашыгы ашарга кирәк. Катнашма бик әче. Шуңа аны чәйгә бутап эчсәң дә була. Имбирне, башка дарулар кебек үк, сак кулланырга кирәк. Ашказаны-эчәк авырулары көчәйгәндә, аны эчми торырга киңәш итәбез.

Фирая ХАРРАСОВА. Сарман

Борчымаса да алмаштырасымы?

?Берничә тешемдәге пломбалар 15–20 ел элек үк куелган килеш тора. Бер көнне танышым аларны даими рәвештә алмаштырып торырга кирәк, дигәч, аптырап калдым. Тештәге пломбаны борчымаса да, алмаштырырга кирәк микәнни?

СУФИЯ апагыз. Казан

Сорауга теш табибы Рөстәм НӘҖИПОВ җавап бирә:

– Тешләрне пломба ярдәмендә ямауның төп максаты тешне бербөтен итеп саклап калырга тырышудан гыйбарәт. Яхшы итеп куелган пломба тешне селәгәй, ризык калдыклары үтеп керүдән сакларга тиеш. Шул рәвешле ул аны бактерияләрдән дә саклый. Заманча пломбалар бик ышанычлы материаллардан эшләнгән. Шуңа күрә алар ун һәм аннан да күбрәк еллар дәвамында хезмәт итәргә мөмкин. Дөрес, моның өчен ямау эше сыйфатлы башкарылган булырга, тешләр даими рәвештә чистартылып торырга тиеш.

Пломбаны алмаштырырга кирәкме-юкмы икәнлеген үзлегеңнән генә ачыклау кыен. Кеше тешкә тел белән кагылганда авырту сизелгән очракта гына хәлнең мөшкел икәнлеген чамалый ала. Бу очракта табибка баруны кичектерергә ярамый. Ул тешләрегезне тикшереп, кирәк дип тапса, иске пломбаны яңасына алмаштырачак.

Киңәш-табыш

БАЛЫК ДЕПРЕССИЯДӘН КОТКАРА

Остеопороз һәм депрессиядән саклану өчен Д витаминына бай ризыклар ашарга кирәк. Аның күплеге буенча сельдь балыгына тиңнәр юк. 100 грамм сельдь балыгында Д витаминының өч көнлек нормасы саклана. Тәрәч балыгының бавырын пешереп ашаган кешегә дә көзге күңел төшенкелеге янамый. Әтәч (лисичка) һәм кәҗә (сморчок) гөмбәләрендә Д витаминының ярты көнлек нормасы бар. Йомырка сарысы да файдалы. Тик аның авырлыгы, күп дигәндә, 20 грамм булуны исәпкә алсак, көнлек витамин өчен шактый йомырканы «корбан итәргә» туры киләчәк. Шуңа күрә йомырка тәбәсе әзерләгәндә, аңа алда телгә алган азык-төлекне дә өстәү хәерле.

БОРЫЧ ШИФАСЫ

Радикулит, ревматизмнан интеккән, буыннары сызлаган кешегә борычлы май ярдәм итә. 200 грамм үсемлек маена 2 аш кашыгы төелгән кара борыч кушып, сүлпән утта кайнатып чыгарыгыз. 5–6 минут кайнаткач, сүндереп суытыгыз. Суыткычта саклагыз. Кулланыр алдыннан кирәк кадәрен генә бераз җылытып, авырткан урынга сеңеп беткәнче сөртегез. Җылы тукыма белән урап, бер-ике сәгать тотыгыз. Бик яндыра башласа, тирене үсемлек маенда чылатылган мамык тампон белән чистартыгыз.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Валентина СЕМЕНОВА

БАШЛАНДЫ!

Апрель – бакчачылар өчен мәшәкатьле һәм мөһим ай. Көзен мул уңыш җыеп алу өчен, иң элек туфракны вакытында әзерләү, аны дөрес итеп тәрбияләү кирәк. Бу җәһәттән нәрсәләрне белеп торырга? Бакчачылыкның нинди хәйләләре бар? «Россельхозцентр» оешмасының Татарстандагы филиалы җитәкчесе урынбасары Гүзәл ХӨСӘЕНОВАдан шул хакта белештек.

shutterstock.com

– Иң элек җирдә эшләү ае бу. Ләкин бакчаны казырга керешкәнче, кайбер серләрен искә төшереп алу зыян итмәс. Артык дымлы туфракны казырга ярамавын аңлатып торасы юктыр. Ләкин казу эшләрен соңга калдырырга да ярамый. Юкса туфрак, комга әйләнеп, кислородсыз калырга мөмкин.

Туфракның өлгергәнме-юкмы икәнен тикшереп карауның гади генә ысулы бар. Туфракны учка алып, кысып карыйбыз. Кечкенә генә кисәкләргә таралса, димәк, казый башларга мөмкин. Таралмаса, артык юеш, ә инде ком кебек коелса, артык кипкән, дигән сүз.

Чүп үләннән котылу

Булачак түтәлләрдәге чүп үләннәрдән котылу өчен нәрсә эшләргә? Бу сорау күпләрне борчый. Кызганыч ки, аларны бетерүнең җиңел генә ысулы уйлап табылмаган әле. Элекке гадәт буенча – казыгач һәм тырмалагач, туфрактан үлән тамырларын җыеп алудан башка чарасы юк. Әлбәттә, мәшәкатьле эш, ләкин чүп үләнне бары тик шулай гына киметеп булачак.

Теплицаны да яңа үсентеләргә әзерли башларга кирәк. Казыганчы, ашлама керткәнче, туфракны зарарсызландырырга онытмагыз. Моның өчен 3 процентлы бордо эремәсе әйбәт. Пыяласын яки пластигын, иренмичә, юып алыгыз. Үсентеләргә яктылык әйбәтрәк төшәчәк!

Тал ботагы серләре

Агач үсентеләре утыртуга килгәндә, бу эшләрне дә нәкъ менә хәзер – апрель урталарында башлап җибәрү әйбәт. Гибискус, спирея кебек чәчәк куакларын, туя, кайбер башка үсентеләрне ботактан үрчетергә уйласагыз, тал ботакларын эшкә җигәргә мөмкин. Берничә тал ботагын (диаметры 1 см чамасы) сулы банкага утыртып, тамырлана башлавын көтәбез. Алар бик тиз тамырлана. Шуннан талны алып ташлап, шул суга утыртасы ботакларны урнаштырабыз. Суын алыштырмыйбыз. Кимесә, бераз өстәргә генә мөмкин. «Таллы» суда ботаклар күз ачып йомганчы диярлек тамыр җибәрә. Шуннан соң аларны башта чүлмәккә, бераз үскәч, даими урынына күчереп утыртабыз. Сүз уңаеннан, чәчәр алдыннан, орлыкларны (чәчәк суганчаларын) да тал суында тотарга, тәрәзә төпләрендәге помидор, борыч үсентеләренә дә шуны сибәргә мөмкин. Талдагы салицил кислотасы бактерияләрне үтерү һәм үсентеләргә сихәт бирү үзенчәлегенә ия.

Бөҗәккә каршы

Җимеш агачлары һәм куаклар кәүсәләрен корткычлардан саклау өчен, бакыр купоросы эремәсен кулланырга мөмкин. Крыжовник, карлыган куакларын кисмәннәрдән (пилильщик – яфракларны җепселләренә кадәр ашап бетерергә мөмкин) коткарып калу максатында, куак төбен йомшарткач, көл кертергә һәм туфрагын рубероид белән капларга кирәк. Ә инде чәчәкләрен койгач, куакка көл яки гәрчич төнәтмәсе бөркибез. Бер атна узгач, тагын шуны кабатларга кирәк.

Суган, кишер ише салкынга чыдам яшелчәләрне утыртырга вакыт җитеп килә. Сүз уңаеннан, орлык суганы утырту буенча халык киңәшләрен дә тәкъдим итим әле. Суган һәм кишер орлыклары, эфир майлары күп булу сәбәпле, авыр тишелә. Шуңа күрә, чәчәр алдыннан, аларны эшкәртергә кирәк. Кайнар суга ярты бал кашыгы чәй содасы өстәп, орлыкларны шунда салырга һәм берәр сәгать тотарга. Шуннан соң, киптереп, түтәлгә 1,5 см тирәнлектәге бураналарга чәчәсе генә кала.

Укучы хатлары

Укроп үстерү хәйләсе

Хуш исле сусыл уңышын мулдан бирсен өчен, беренчедән, нашатырь спирты белән тукландырам. Азотка бай булуы нәтиҗәсендә үсентеләрнең шаулап үсүенә китерә ул. 1 литр суга 1 чәй кашыгы препарат салырга кирәк. Түтәлгә шуны бөрким. Икенчедән, шытымнар барлыкка килгәч, көл эремәсе кертү (1 чиләк суга 1 стакан көл) әйбәт. Монысын тамырларына сибәм. Шул рәвешле укроп бик мөһим калий һәм фосфор матдәләрен алачак.

Тукландыру эшен орлык чәчкәннән соң (чәчкәнче, бераз бүрттерәм) ике атна чамасы узгач башлап җибәрәм. Алга таба һәр ике атнадан соң шушы эшне кабатларга тырышам. Бу киңәшне тотканда, укроп искитмәле дәрәҗәдә шәп үсә.

Нажия СӘЛИМОВА. Казан

Эре һәм сусыл редис

Бакча күршеләрем редисканың ук җибәрүеннән яки эче куыш булып үсүеннән зарлана. Ә минем беркайчан да болай булганы юк. Һәрвакыт гади генә кагыйдәләрне үтәргә тырышам чөнки.

Түтәл өчен узган елда тирес күбрәк кертелгән урынны сайлыйм. Болар – помидор, борыч, кыяр, баклажан түтәле булырга мөмкин. Кәбестә бу исемлеккә керми, чөнки редис белән «туган» булганлыктан, яшелчә елеге туфракта начар үсәчәк. Черемәгән тирес редиска начар тәэсир итә, шуңа күрә черегәнен кулланырга кирәк.

Шытымнар күренүгә, 5әр сантиметр ара калдырып, сирәклим. Тыгыз утыртылган редис уңышы начар була.

Түтәлгә күп итеп су сибәм. Вигрәк тә тишелгәнче һәм шытымнар әйбәтрәк үсеп киткәнче. Бу җәһәттән миңа язгы яңгырлар бик әйбәт булыша.

Әлеге кагыйдәләрне үтәү 1 кв. м мәйданнан чама белән 2 кг эре, сусыл редис уңышы җыю мөмкинлеге бирә.

Нурания СИБГАТУЛЛИНА. Питрәч районы

Белсәң, зыян итмәс

Сипкелле буласы килми

Язгы кояш матур итеп карый башлауга, сипкелләр күбәя. Аларны бераз гына «йөгәнләү» серләре бар. Бу җәһәттән лимон, кыяр, петрушка согы ярдәмгә килачәк.

Моның өчен иң элек шушы ингредиентларның берсен (барысын бергә дә ярый) блендерга салып ваклыйбыз. Согын марля аша сөзеп, суыткычка куябыз. 2–3 көн дәвамында суыткычта бик әйбәт сакланачак. Кичен битне шуның белән чылатабыз. Җиңелчә генә ышкыйбыз. Иртә белән кояштан саклану кремын сөртәбез. Согын сыкканнан соң калган түпкә каймак өстәп (1:2 нисбәтендә) болгатабыз. Кичен шушы катнашманы биткә сылыйбыз һәм 15–20 минут тотабыз. Атнага 2–3 тапкыр шулай эшлибез.

Аш-су

ЧӨГЕНДЕР ҺӘМ КӘБЕСТӘДӘН ЯЗГЫ САЛАТ

ХАЛИСӘ МИҢНУЛЛИНА РЕЦЕПТЫ

Язгы витамин җитмәү чорында организм өчен бик файдалы ризык бу.

Кирәк булачак: уртача зурлыктагы 2 кызыл чөгендер, 200 грамм кәбестә, 2 данә әстерхан чикләвеге, 1 чәй кашыгы лимон согы, 1 чәй кашыгы шикәр комы, 2 аш кашыгы зәйтүн мае, тәменчә тоз, кара борыч.

Чөгендерне юып пешерәбез. Суынгач, кабыгыннан чистартабыз һәм корейча кишер әзерләү өчен кулланыла торган угыч аша чыгарабыз. Кәбестәне, юып, вак кына итеп турыйбыз. Чөгендер һәм кәбестәне бергә салып болгатабыз, лимон согы, тоз, шикәр комы, борыч һәм зәйтүн мае өстибез. Барысын бергә әйбәтләп болгатып, 20 минут суыткычта тотабыз. Табынга куйганда, өстенә чистартылган чикләвек (бераз кыздырып алсагыз, тагын да тәмлерәк булачак) сибәбез.

Киргә чыгар

ЖАЛЮЗИ ҖИҢЕЛ ЮЫЛА

Тимер пәрдәне юу-чистарту – бик мәшәкатьле эш. Һәрбер пластинасын сөртә-сөртә арып бетәсең... Эшне ничек җиңеләйтергә? Беркетелгән урыныннан салдырып алырга да, ваннага су тутырып, кер порошогы салып, шунда бераз тотарга. Аннан соң чайкап алырга. Ярты сәгать эчендә жалюзи чип-чиста булачак!

ЯҢАРТЫП ҖИБӘРӘБЕЗ

Бу якшәмбедә – православие динен тотучыларның Пасха бәйрәме. Йоласы – гадәттә суган кабыгы кайнаган суга салып, йомырка буяу. Кайбер районнарда мөселманнарда да яшәп килә әле ул. Дин буенча түгел, әлбәттә, ә балаларга кызык булсын өчен. Йомырканы шул рәвешле буягач, суган төнәтмәсен агачтан эшләнгән кухня кирәк-ярагын яңартып җибәрү өчен кулланырга мөмкин. Төнәтмәне сөзеп, агач кашык, куна тактасы, «подставка» ише әйберләрне шуңа салабыз. 5–7 минут тотабыз. Аннан соң, төнәтмәдән алып, краннан агып торган су астында чайкатабыз. Газетага салып киптерәбез. Соңыннан кухня кирәк-ярагы өслеген үсемлек маенда чылатылган мамык кисәге белән сөртеп алабыз.

АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘ РИЗАЛЫГЫ ӨЧЕН

Аллаһы Тәгалә мөэминнәр хакында: «Алар (үз мал-мөлкәтен) сарыф иткәндә исраф итми һәм саранлык күрсәтми, ә моның (ягъни исраф итү белән саранлыкның) арасында урталыкны тота», – ди. Өммәтебезнең тагын бер күркәм сыйфаты – уртаклаша, бүлешә белү дә. Рамазан ае моны тагын бер кат расларга ярдәм итә. Мөселманнар бу айда фитыр, фидия сәдакаларын бирә, малыннан зәкят чыгара.

dumrt.ru

Фитыр, фидия һәм зәкят турында кызыксындырган сорауларга Алмаз хәзрәт ГАЛИМҖАНОВ ачыклык кертте.

:: «Зәкят» төшенчәсенә аңлатма бирсәгез иде. Нәрсә ул? Аны кемнәргә бирү мәҗбүри?

– Ислам динендә кешене акчасыз калдыру максаты юк. Кеше финанс мөмкинлекләренә карап өлеш чыгара. Аллаһы Тәгалә **зәкят** турында бик күп урында искә алып, бу хакта Коръәни Кәримдә хәбәр итә. Бу – «чистарыну» дигән сүз, ягъни малны чистарту. Ул – исламдагы биш багананың берсе. Намазны, уразаны калдырган кебек үк, мөмкинлегең булып та, хаҗ кылуны яисә зәкят түләүне калдырсаң, гөнаһ санала.

Зәкятне мөмкинлеге булган, 85 грамм алтын, йә булмаса, 595 грамм көмешкә ия кешеләр түли. Ягъни ул бернәрсәгә дә тотылмый торган 454 мең сум акчасы булганнарга кагыла. Кешенең шул күләмдә малы җыелган икән, зәкят түләргә тиешле. Шунысы да бар: зәкяткә дигән өлеш кешенең тормыш ихтыяҗларына, бурычларына, сәламәтлегенә дигән акчадан тыш малдан чыга. Күп кеше зәкят, фитыр, фидия күләмен күргәч: «Ничек без шулкадәр түләргә тиеш?» – дип әйтергә мөмкин. Шуңа күрә шәригать мөмкинлеге булган кешегә дип искәртә. Пенсия акчасына гына яшәгән кеше моны берничек тә түли алмый, билгеле. **Зәкят елга бер тапкыр гына түләнелә.** Әйтик, ул зәкятен хәзер түләп куя да ел буе бурычка батып яши икән, бу дөрес түгел. Кешенең зәкят түләрлек мөмкинлеге юк икән, ул түләргә тиешлеләр исемлегеннән төшеп кала. **Зәкят мескен, фәкыйрь, ятим кешеләргә бирелә.**

:: Хәзер халыктан фитыр һәм фидия сәдакалары турында сораулар күп килә. Алар турында да тәфсилләбрәк аңлатсагыз иде.

– **Фитыр – мохтаҗ булмаган мөселманның мохтаҗларга бирелә торган сәдакасы.** Ул – савaплы гамәл. Аны һәр мөселман, ураза тотса-тотмаса да, тапшыра. Фитырны без **гаеткә кадәр** бирәбез. Ни өчен? Чөнки ураза тоткан вакытта без кирәкмәгән гамәлләр кылырга мөмкинбез. Шулардан котылу, чистарыну, күңелдә тынычлык урнашсын өчен, пәйгамбәребез (с.г.в.) фитыр сәдакасын бирергә кушкан. Фитыр сәдакасын түләп, уразабызны камилләштерәбез генә. Пәйгамбәребез (с.г.в.) үз вакытында моны бодай, арпа белән биргән. Хәзер акчалата бирәбез. **Фитыр күләме – 150 һәм 800 сум.**

Фидия – ураза тотмаган көннәр өчен бирелә торган сәдака. Әгәр мөселман билгеле бер сәбәпләр аркасында ураза тота алмый икән, ул фидия түли. Фидия ул – бер кешене ачтан үлмәслек итеп бер көнлек ашату. Аны акчалата да бирергә мөмкин. **Бу билгеле бер сумма – 350 сум.** Түли алмаган очракта, Аллаһы Тәгаләдән тәүбә сорап, Аңа тәвәккәллибез. Аллаһы Тәгалә – Кичерүче һәм Гафу итүче.

Бу сәдакаларны бирми калу гөнаһ санала. Әмма кеше үзе дә фәкыйрь, очын очка ялгап яши, авыру икән, бу түләүләр аның өстеннән төшә.

Сәдаканы тапшыру өчен махсус оешмалар бар. Мәчетләргә дә җыялар. Авыру кешеләр, ялгыз пенсионерлар, мескеннәр, бурычка баткан кешеләр, гыйлем юлында булган шәкертләр, авыр тормыш хәлендә калганнар күпме! Кеше сәдаканы үзе тапшырса хәерле.

Ураза көндәлеге

? Тәравих намазы ничә рәкәгать укыла?

– Татарстан мәчетләрендә тәравих намазы Хәнәфи мәзһәбе буенча 20 рәкәгать итеп укыла. Кем дә кем рамазан аенда тәравих намазын калдырса яки егерме рәкәгатьтән киметеп кыскартса – сәхабәләрнең бердәм фикеренә каршы килгән гамәл кыла, бу гамәлдән мөмкин кадәр читләшергә кирәк.

? Ураза тотканда музыка тыңларга, фильм карарга рөхсәтме?

– Беренчедән, музыканы озак тыңлау Коръәнне йөрәктән ерагайта һәм бушата. Икенчедән, музыка бу дөньяга карата мәхәббәт һәм бәйлелекне арттыра, шул рәвешле ахирәттән ерагайта. Рамазан аенда вакытны Коръән уку һәм игелекле эшләр башкаруга юнәлтү хәерлерәк. Бу ашау-эчүдән генә тыелу вакыты түгел. Бу – тәрбия, үзеңне рухи яктан үстерү дә.

? Рамазан аенда никах укытырга ярыймы?

– Ярый. Әмма көндезге сәгатьләрдә мәҗлес оештырмагыз. Ашау-эчүне кояш баеган вакытка калдырыгыз. Шунысын да онытмагыз: рамазан аенда көндезге сәгатьләрдә ир белән хатын арасында җенси мөнәсәбәт тыела.

Гыйбрәт ал!

Ризык сыя, сер сыймый

Бер кеше Хәсән Басри хәзрәтләренең янына килеп: «Фәлән синең турында начар сүзләр әйтте», – диде.

– Кайчан?

– Бүген.

– Кайда?

– Өеңдә.

– Аның өеңдә нишләдең?

– Кунакка бардым.

– Кунакта нәрсә ашадың?

Ул кеше сигез төрле ризык исемен санады.

Шунда Хәсән Басри:

– Ул адәмнең сигез төрле ризыгын эчеңә сыйдыргансың, ә бер сүзе сыймадымы? Чык моннан, – диде һәм гайбәтчене куып чыгарды.

dumrt.ru

Хикмәтле сүз

Мәчет әдәпләре

Илдар Мөхәммәтҗанов

- «Мәчетләрегезне сабыйлардан, диваналардан, сату-алу эшләреннән, низаг-талашлардан, тавыш күтәрүдән саклагыз».
- «Мәчетләр Аллаһны зекер итәр өчен һәм намаз укыр өчен генә төзелде».
- «Коръән укылганда шауламыйча тыңлагыз: сез Аллаһның ярлыкавына юлыгырсыз».
- «Әй, Адәм балалары, намаз укый торган урынга барганда һәрвакыт пакь киемнәр киегез; ашагыз, эчегез, ләкин (артыгын) исраф кылмагыз. Аллаһ исрафчыларны сөйми».
- «Мәчетләр – Аллаһның җирдәге йортлары. Мәчеткә үзен зиярәт кылырга килүчене Аллаһ, әлбәттә, хөрмәт кылыр».
- «Барча мәчетләр – бары тик Аллаһка гыйбадәт кылу урыны. Шуңа күрә, сез Аллаһка тиң дип, һичбер башка затка табынмагыз».
- «Җир йөзендә Аллаһка иң сөекле урыннар – мәчетләр, иң сөйкемсез урыннар – базарлар».

Йөгез, бер дога!

БӘРӘКӘТ СОРАП УКЫЛА

Еш кына адәм баласы шөкер итәргә оныта. Алай гына да түгел, ризасызлык белдерә: җитәрлек дәрәҗәдә сәламәт, бай, матур, уңышлы түгел без, дибез.

Яшәгән йортның киң, ризыгыбызның мул булуын, бәрәкәт теләсәк, шушы доганы кылырга кирәк:

«Аллаһуммә-гъфирлий зәнбий үә үәссиг лий фий дәәрий үә бәәриклий фий ризкый».

Яңа закон нигезендә, 18 яше тулмаган кешегә вейп сату тулысынча тыела. Чикләүләр моның белән генә бетми әле. Вейпларны, шул исәптән никотинсыз матдәләрне ярминкәләрдә, күргәзмәләрдә, дистанцион ысул яки автоматлар аша сату мөмкин булмаячак. Аларны вакллап сату кибетләрендә генә сатарга ярый. Әмма бу очракта да махсус шартлар үтәлергә тиеш. Вейпларны кибет киштәсенә ачыктан-ачык кую, күрсәтү тыела. Моннан тыш аларны сатканда ташлама ясарга, рекламаларга да ярамый.

Россия Дәүләт Думасында Татарстаннан депутат Айрат Фәррахов белдерүенчә, әлеге закон, иң беренче чиратта, балигъ булмаганнарның сәламәтлеген саклау, аларны никотинлы матдәләр йогынтысыннан аралауны күздә тота.

– Әлеге закон белән беррәттән, безгә Евразия икътисадый берлегенә кергән илләрдә тәмәкегә каршы законнарны, акциз сәясәтен дә көйләргә кирәк. Юкса безнең барлык тырышлыгыбыз бушка булачак, – ди депутат.

Күптән көтелгән законның нәтиҗәле булачагына ышанасы килә. Юкса саннар шактый куркуга сала. Россия белем бирү академиясе белгечләре күптән түгел яшьләр арасында сораштыру уздырган. Аның нәтиҗәләренә ышансаң, бүген илдәге үсмерләрнең 35 проценты даими рәвештә баллы көпшә суыра.

Үзеңнән башлыйсы

Казан шәһәренең 12 нче гимназиясендә 11 сыйныфта укучы Зилә Хәбибуллина фикеренчә, яшьләр бу начар гадәткә модадан калышмаска тырышып ияргә.

– Хәзерге яшьләр бик актив. Аларга һәрчак яңа хисләр, мөмкинлекләр кирәк. Күпләргә вейп тарту ниндидер үзгә мохит тудыру кебек тоела. Әмма бу – ялгыш фикер. Тормышыбызда күпкә яхшырак, күңеллерәк әйберләр, мөмкинлекләр дә бар бит. Яшьләр күбрәк шуларга игътибар итсен иде. Яңа закон бу проблеманы бетермәс дип уйлыйм. Вейп тартырга уйлаган кеше аны барыбер таба алачак, – дип саный булачак студент кыз.

Татарстан Иҗтимагый палатасы әгъзасы, «Татарстанның күпбалалы гаиләләре» төбәкара иҗтимагый оешмасы рәисе Артем Кузнецов та шул фикердә.

– Бәйлелектән закон ярдәмендә генә котылып булмый. Вейп тартасы килгән үсмер аны барыбер кулга төшерәчәк. Бигрәк тә янәшәдә аны көйрәткән кешеләр булганда, бу әллә ни зур авырлык тудырмаячак. Әгәр син балаңның вейп тартмавын телисең икән, син, иң беренче чиратта, моны үзең эшләмәскә тиеш. Ә бүген күреп торабыз: олысында да, кечесендә дә шул әйбер. Элегрәк хатын-кызлар мондый начар гадәте булса, уңайсызлана, аны кеше күзенә күренмәслек итеп эшләргә тырыша иде. Ә хәзер гүзәл затларга кадәр демонстратив рәвештә, тыныч күңел белән тәмәке, вейп көйрәтә, – ди күп бала әтисе. – Өлкән кешенең начар гадәте булса да, ул моны аңлап, организмга ни дәрәҗәдә зыян салуын белеп эшли. Үсмерләр исә моны аңлап бетерә алмый. Шуңа күрә балигъ булмаган балаларга вейп сатуны закон дәрәҗәсендә тыюлары бик яхшы.

Үпкә сынала

Белгечләр, вейп әле ахыргача өйрәнелеп бетмәгән табышмак дип ышандырырга тырышса да, тормышта аның зарарын исбатлаган аянычлы очраклар булып тора. Хәтерләсәгез, моннан берничә ел элек Алексеевск районында электрон тәмәке тартканнан соң 15 яшьлек баланың гомере өзелгән иде. Узган ел исә бер егетнең кулында вейп шартлады. Моннан дүрт ел чамасы элек Америка табиблары вейп тарту белән мавыккан 17 яшьлек егеткә яңа үпкә күчереп утыртты. Дистә еллар дәвамында шундый катлаулы операция ясаган табиблар шаккаткан: вейп тарту аркасында егетнең үпкәсендә купсанлы төерләр пәйда булган, үпкә тукымасының яртысыннан артык өлеше «үлгән», калган өлеше исә таш шикелле тыгызланып каткан. Сүз уңаеннан, вейп тарткан кешенең үпкәсе шартлаган попкорны хәтерләтүен дә нәкъ менә АКШ галимнәре ачыклады.

Күптән түгел Корея галимнәре вейпның бер капсуласында бер кап тәмәкедәге кадәр никотин барлыгын ачыклаган. Соңгы елларда уздырылган тикшеренү нәтиҗәләреннән күренгәнчә, вейплар үпкә авырулары килеп чыгу ихтималын – 50 процентка, инсульт куркынычын 71 процентка арттыра.

Электрон тәмәкенең гадәтиеннән ни дәрәҗәдә зыянлырак булуын тулысынча ачыклап бетерү бик кыен, ди белгечләр. Ник дигәндә, гадәти тәмәке зыянын тикшергәндә, нигездә, никотинның сәламәтлеккә салган зарары турында сүз бара. Электрон тәмәке, вейплардагы сыекчада исә күптөрле ис һәм тәм керткечләр кулланыла. Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасыннан алынган саннарга ышансаң, электрон тәмәкедә 15 меңләп төрдәге тәм керткеч кулланыла.

Сабак булсын

Татарстан Дәүләт Советының яшьләр парламенты рәисе Нина Шимина яңа закон яшьләрнең генә түгел, ата-аналарның да күзләрен ачар дип өметләнә.

– Без мондый закон кертү тәкъдиме белән 2019 елның ноябрендә үк чыккан идек. Ләкин ул чакта яклау тапмады. Шуңа күрә бу законның өч елдан булса да кабул ителүенә бик шатландык. Җәйге лагерьлар өчен җаваплы кеше буларак, моңа аеруча сөендем. Юкса соңгы арада балалар арасында вейп тартучылар саны коточкыч дәрәҗәдә арткан иде. Элегрәк алар лагерьга килүгә үк вейпларын җыеп ала идек тә киткәндә ата-анасына тапшыра идек. Аларның күбесе баласының мондый начар гадәте барлыгы турында бөтенләй хәбәрдар түгел, вейпны күргәч, югалып калалар иде. Ә хәзер ата-ана үзе үк баласына вейп сатып ала башлады, – ди яшьләр парламенты рәисе.

Дөрес, вейп тарткан баланың бу начар гадәтеннән тиз генә котыла алачагына шикләнеп карый ул. Аны сату тыелган очракта да, кулга төшерү юлларын табачак.

– Якын арада вейпны «идән асты»ннан сатучылар да пәйда булырга мөмкин. Әмма әлеге законның иң мөһим бер ягы бар. Аның ярдәмендә җәмгыятьтә акрынлап, вейп тарту куркыныч, дигән фикер урнашачак. Чикләүләр кертелгәч, күпләр моны ахыргача аңлап бетерер, тыйганнар икән, димәк, дөрестән дә зыянлы, дип уйларлар дип өметләнәм, – ди Нина Шимина.

Аңлаганда, соң булмасын

Язманы әзерләгәндә, интернеттагы вейп темасына багышланган форум, постлар белән дә танышасы иттек. Ә андагы хәлләрдән чәчләр үрә торырлык! Вейпның зарары турында язылган һәр мәкалә астына аны куллланучылар нәрсә генә язып бетермәгән! Вейпның файдадан күп нәрсәсе юк, янәсе. Берәү әнә, вейп тарта башлагач, баш авыртудан котылган, икенче берсенең күз күрүе яхшырган, аяктагы чыгып торган кан тамырлары рәткә кергән. Күбесе – 15–25 яшь аралыгындагы кешеләр. Кисәтүгә колак саласы урынга, вейпның зыяны турында мәкалә язучыга биш куллап ябырылган алар.

Әлмәт үзәк район хастаханәсенең табиб-пульмонологы Рөстәм Насретдиновны «дәүләт заказы», «тәмәке җитештерүче оешма кушуы» буенча вейпны хурлап утыруда гаепләгәннәр әнә. Табиб исә бу сүзләрне күңеленә якын алмый. Ул, кешеләр вейпның ни дәрәҗәдә зарарлы икәнен аңлаганда, соң булмасын иде, дип кенә борчыла.

– Кызганыч, вейп тарту бик тиз арада модага әверелде. Бигрәк тә яшьләр арасында тиз таралды. Күпләрне тәмле булуы, аны хәтта бина эчендә тартырга рөхсәт итүләре белән дә җәлеп итте ул. Әмма бит аның чынлыкта нәрсә икәнен яшьләр түгел, белгечләр дә тәгаен белеп бетерми. Тәмәкенең үпкә, бронхларга бәйле авырулар, яман шеш китереп чыгаруы күптән фәнни расланган. Вейпларның составында ниләр барлыгы да, аның организмга салган зыяны да тиешенчә өйрәнелеп бетмәгән. Шуңа күрә үсмерләргә вейп сатуны закон дәрәҗәсендә тыюлары бик яхшы. Әмма аны балигъ булганнар арасында чикләү юлларын да эзләргә кирәк, – дип саный табиб.

Вейп кулланучылар сафының «яшәрә» баруына да борчыла ул. Әле күптән түгел генә Рөстәм Насретдиновка вейп тарту аркасында үпкәләре зарарланган сигез яшьлек (!) малайга ярдәм итәргә туры килгән.

– Хроник үпкә авырулары булган, бронхиаль астмадан интеккән кешеләр өчен вейп, электрон тәмәке тарту аеруча куркыныч. Аларны тартканда кан тамырлары, югары сулыш юллары кысыла. Шул мизгелдә янында ярдәм итәр кешесе булмаса, кеше үлеп тә китәргә мөмкин, – ди табиб.
– Аннары моның тагын бер куркынычы ягы бар. Яшьләр арасында бер вейпны, гадәттә, берничә кеше тартырга мөмкин. Кешедән кешегә йөрткәндә аның аша герпес, туберкулез кебек куркыныч чирләр, вирус, инфекцияләр дә йогарга мөмкин.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ВЕЙП СЫЕКЧАСЫ СОСТАВЫНДАГЫ БИЛГЕЛЕ МАТДӘЛӘРНЕҢ ОРГАНИЗМГА ТӘЭСИРЕ

МАТДӘ	ЗЫЯНЫ
Пентабромдифениль эфир	Калкансыман биз эшчәнлеген боза.
Тәм керткеч, авыр металлар	Кешенең үсүе, үрчүе, үз-үзен тотышы өчен җаваплы эчке секреция гормоннарын сафтан чыгара, бронхиаль астмага китерә.
Пропиленгликоль	Бөер, бавырга бәрә.
Никель, кургаш	Нерв, эндокрин, ашкайнату системасы эшчәнлеген боза. Йөрәкне, сидек юлларын сафтан чыгара.
Глицерин	Хәтер начарлана, кеше игътибарсызга әйләнә.

Зиһенгә бәрә

Вейпка бәйлелектән котылып буламы? Шул сорау белән психотерапевт, психиатр-нарколог Марс САРЫгa мөрәҗәгать иттек.

:: Вейп тарту белән мавыккан үсмерне киләчәктә нәрсә көтә?

– Электрон тәмәке аэрозоле составындагы никотин кан тамырларын кыса. Җитлегеп бетмәгән организм өчен бик зур сынау бу. Кан тамырлары кысылу аркасында балада йөрәк өянәге булырга мөмкин. Электрон тәмәкедә бер кап тәмәкедәге кадәр никотин булуын исәпкә алсаң, моңа аптырарлык түгел, билгеле. Аннары шунысы да бар: кешенең баш мие 25 яшенә генә тулысынча җитлегеп бетә. Шуңа кадәр электрон тәмәке, вейплар белән мавыккан яшүсмер баш миенең префронталь өлешендә киләчәктә җитди үзгәрешләр башланачак. Баш миенең әлеге өлеше кешенең фикерләү сәләте, зиһен, карарлар кабул итү өчен җавап бирә. Димәк, вейп, электрон тәмәке белән мавыккан үсмерне киләчәктә әнә шундый авырлыклар көтә.

:: Вейплар бәйлелек китереп чыгарамы? Аннан котылып буламы?

– Составында никотин булган вейп, электрон тәмәке физик һәм психологик бәйлелек тудыра. Аларны никотинлы тәмәке тарткан кешегә ярдәм иткән кебек дәвалыйбыз. Никотинсыз вейплар организмның билгеле бер өлешләренә зыян сала, психологик бәйлелек китереп чыгара. Бу очракта еш кына психотерапевтка да мөрәҗәгать итәргә туры килә. Соңгы арада бу максатта дәвалаучы вейплар да кулланыла башлады. Аларның составында каннабидиол мае, төрле үсемлек майлары, биологик актив матдәләр бар. Алар бар да төрле бәйлелектән, шул исәптән никотинга тартылудан да котылырга ярдәм итә. Әмма мондый төр дәвалаучы вейпларны табиб кушуы буенча гына кулланырга рөхсәт ителә.

Гөлгенә
ШИҺАПОВА

МЕҢ КЕШЕГӘ – БЕР КҮРӘЧӘК

Монда килүчеләрне әллә каян танып алалар. Араларында бишәр ел буе бер сукмакны таптаучылар да бар. Барысын да тамак йөртә. Җылы ризык ашар өчен бирелдә чиратка алдан ук тезеләләр. Тәртип бозу юк. Ашыкмыйча башта берсе, аннан соң икенчесе килеп, ризык ала. Кире киткәндә исә рәхмәт укыйлар. «ВТ» журналисты, Казандагы «Приют человека» үзәгендә мохтаҗларның хәлен белешеп, аларның күңелен күрергә тырышты.

Бүген өй, иртәгә урам

Башка вакытта бирелдә кешеләрне ике тапкыр – иртән һәм кич табын янына җыялар. Рамазан аенда исә кичке алтыдан соң ашыйлар. Соңга калып бармасак та, без килгәндә, чират җыелган иде. Башта приютта яшәүчеләрнең хәлен белергә уйладык. Узган килүебез белән чагыштырганда, шактый үзгәрешләр дә булган. Приютка яңа вагоннар кайткан. Кечкенә генә бакчаларына ике теплица да урнаштырып куйганнар. Бер җирдә чәч кистерү бүлмәсе, табибныкы да бар. Мунчаларын, кер юдырта торган бүлмәләрен дә карап чыктык. Урамда яшәү түгел инде. Тик җылысы гына юк! Гаиләң белән түгәрәкләнеп яшәүгә җитми. Хәер, мондагылар «гаилә» дигән сүзне яратмыйлар. Чөнки якыннары белән бер куышта тормыш кора алмаган, шуның аркасында өеннән чыгып киткәннәр, торыр урынсыз калганнар күп монда.

Узган ел күрешкән абый-апалар исәнсаулармы икән? Фәрит абый өйләнгән, Мария түтине балалары килеп алган. Калганнары әле дә монда, үзләре танып алды.

Кызлар бит әле!

Бүлмәләрнең күбесе бикле. Анда яшәүчеләр эштә икән. Кайсы урам себерә, кайсы җыештыручы булып эшли. Пилмән ясаучылар да бар. Теләге булган кешегә эш табарга ярдәм итәләр.

Күрше бүлмәдә ике Надя һәм бер Нина яши. Сөйләшергә яраталар, фотога төшәргә дә берсүзсез ризалашты алар. Ә миңа язмышларын сөйләшә башлагач, елап ук җибәрделәр. Өч кешегә – бер күрәчәк. Өчесен дә урамга якыннары куып чыгарган. Алар сөйли, ә миндә каз тәннәре чыга. Башымда – мең төрле уй. Ничек инде балаң куып чыгара?

Беренче Надя – Яшел Үзәннеке. Карт түгел әле ул, 60 яшен яңа тутырган. Тәбәнәк кенә ханым җыештыручы булып эшли икән.

– Кызым фатирымны хосусыйлаштырган да куйган. Мине өлешкә кертеп тә тормаган. Берзаман әйтми-нитми сатты да җибәрде. Үзе Казанга күчте, мин урамда калдым. Яшәргә урын табарсың әле, диде. И, ул чакта күргәннәрем! Эчкече хатын иттеләр. Урамда калгач, бөтен кеше шулай уйлый инде. Иң кызыгы: мин бомжлар арасына да керә алмадым. Кабул итмәделәр. Аларның да үз кануннары бар, – ди Надя. – Башта бер туганыма бардым. Ярты ел яшәгәч, фатир эзләргә куштылар. Хезмәт хакым 14 мең сум иде. Чыгып китәргә туры килде. Аннан соң икенчесенең ишегең шакыдым. Анысы бөтенләй кертмәде. Ишек ярыгыннан карады да, кит, диде. Мин Казанга чыгып киттем. Әле ярый, приютны тиз таптым. Бик рәхмәтлемен. Минем өчен җәннәткә тиң бу.

Икенчесе буйга да озынрак, чибәрлеге дә күз явын алырлык. Үзем дә сизмичә: «Сез – бик матур ханым», – дип сүз башладым.

– Булма чибәр, бул бәхетле, – диде Надя. – Шул чибәрлек харап итте инде мине. Матур хатынга ирләрнең күзе төшә. Миңа да ошыйлар иде. Ирем белән Самарада яшәдек. Балаларым булмады. Ирем үлгәч, бергә төзегән йортыбызны туганнары тартып алды. Акчам булмагач, юрист яллый алмадым. Миңа шулай урамда каласың икән инде.

Ә Нина – бу бүлмәдә иң елагы. Ул сөйләгәндә, мин дә сытылдым әле, башкалар да кушылды. Тыныч кына тыңлап булмый.

– Кызым кызык итте. Бер генә балабыз булды безнең. Узган ел җәй көне ирем суга батты. Ул үлгәч, кызым фатирны миңа әйтмичә саткан. Яңа хуҗалар килгәч, елый-елый чыгып киттем. Кызымны күргән юк. Күрәсе дә килми инде. Әмма ана үз баласына начарлык теләми ул. Мин инде аны күңелемнән гафу да иттем. Йөрәк өзгәләнсә дә, кичерәсең икән. Үзенең дә ике баласы үсеп килә. Белемен дә биргәнбез, башкасын да. Ә килачәген уйларга өйрәтмәгәнмен, – ди ул. – Күршеләремне, дусларымны бик сагынам. 62 яшемне монда каршыладым. Иртән эшкә чыгып китәбез дә кич кайтып йоклыйбыз. Шартлар яхшы. Безне сыендырган приют җитәкчеләренә мең рәхмәт!

Күрше бүлмәдә Валентина үзе генә утыра. Машина бәрдергәч, үткәнен оныткан хатын ул. Исемен дә белми, яшәгән йортын да. 4 ай хастаханәдә ятканнан соң, аңа приютка барырга киңәш итәләр. Мондагы табиблар Валентинаны дәвалый. Әкренләп хәтере яхшыра башлаган.

– Бирелдә документларымны ясатып бирделәр. Шунысы өчен бик рәхмәтлемен, – ди ул. – Кызым мине озак эзләгән. Беркаян да таба алмагач, инде исән булуыма өметләнмәгән дә.

Бүлмә эчендә уйга чумдым. Ярый әле мине озатып йөрүче Лилия айнытып җибәрде: «Ашатырга вакыт».

Монда барысы да уртак...

Илдар Мөхәммәтҗанов

2022 ЕЛДА «ПРИЮТ ЧЕЛОВЕКА» БАШКАРГАН ЭШЛӘР:
♥ 386350 порция җылы ризык әзерләнгән ♥ 1020 комплект кием бирелгән ♥ 10239 кеше төн кунып чыккан ♥ 103 кешегә бушлай юридик ярдәм күрсәтелгән ♥ 30 кешенең документлары яңартылган ♥ 7841 ризык җыелмасы өләшенгән ♥ 5712 тапкыр мунча керткәннәр ♥ 229 тапкыр социаль патрульгә чыкканнар ♥ 12 кешене айнытканнар ♥ 1 кеше наркология диспансерында дәваланган.

«Бүген яңа кешеме?»

Көндәлек эшләп тә карыйсы килде. Лилия белән аш бүлү бүлмәсенә уздык. Иң элек курткамны салып куйдым. Башка яулык бәйләдем. Кулларымны дезинфекцияләдем. Аннан пирчәткә кидем дә эшкә тотындым. Лилия бик ачык кеше булып чыкты. Тиз генә бөтенесен аңлатып та бирде. Ул ризыкны салып тора, мин килүчеләргә тәрәзә аша бирел торам. Шул арада Лилия бирелдәге хәлләрне дә сөйли. Ризыкны Кабан арты мәчетендә пешереп җибәрәләр. Рамазан аенда көн саен җиләк-җимеш таратырга тырышалар. Иганәчеләр гел китереп тора. Пәнҗешәмбе көнне пылау пешерәләр. Бу көнне ризык сорап килүчеләр күп икән. Лилия барлык килгән кешенең исәбен ала. Гадәти көннәрдә 200әр кеше ашатсалар, рамазан аенда 150ләп кеше килә, ди. Бу бит әле бер урында гына. Ә Казанда «Приют человека»ның 6 үзәге бар. Көнгә алар меңнән артык кеше ашата. Сүз уңаеннан, исерек килеш килгәннәрне кертмиләр. Таләп шундый, йә ашыйсың, йә эчәсең инде. Без барда бер ир-ат килгән иде. Айнып килергә куштылар.

Авыз ачу вакыты җитте. Ризык алырга кеше чираты белән генә килеп баса. Иң элек бер ир-ат килде. Лилия әле монда ике ай гына эшләсә дә, бөтенесен исемләп танып тора: «Исәнме, Наил абый! Нәрсә ашыйсың, ашмы, ит белән макароныы?» Авызында теше дә калмаган абый аш сорады. Мине күргәч, каушабрак та китте: «Бүген яңа кешеме әллә?» Шул арада исемемне сорады, ни дисәң дә, егет кеше бит! Башта абыйга ипи, мандарин бирәм. Аннары Лилиянең кулыннан алып, Наил абыйга ашлы тәлинкә сузам. Ул арада Лилия чәй ясый.

Наил абыйга 63 яшь икән. Дәрвишләр бистәсеннән килеп йөри. Бер дә өйләнеп карамаган.

– Минем инвалидлык бар. Электричкада бушлай йөрим. Утырам да киләм. Монда ашау тәмле. Әни үлгәч, ялгыз калдым. Өем бар, тик миңа иптәш юк. Иәләндем инде ялгызлыкка. Сеңлем, беләсеңме, мондый җылы ризыкны күптән ашамаган кеше бит мин, – ди ул.

Наил абый артына баскан Рауза исемле апа уразасын калдырмаска тырыша. Авыз ачар өчен ризык алырга килгән.

– Авыр яшим, балам. Улым авыру. Акчабыз җитми. Үзең беләсең бит инде. Квартплата уникe мең сум булды. Березнең пенсиясе шунда китә. Калган акчага дару да кирәк, ашыйсы да килә. Әле ярый, монда бушлай ашаталар. Биргәннәренә шөкер. Кайчак алар, мине кызганып: «Апа, монда ашап кайт», – диләр. Оялам бит. Икешәр порция алып кит, әле аша да. Шушы ризык белән авыз ачам, шуның белән сәхәр ашыйм. Пешерүчеләргә савап булсын, – ди Рауза апа.

Язмышларның төрлесен күргән булсам да, һәр яңасы кабат тетрәндерә. Ике кулында да бармаклары булмаган бабайны күрүем булды, тагын катып калдым. Ярый, Лилия үткен, кулыма чүмеч тоттырды. Бу абзыйның тәмлерәк итеп сыйлыйсы килде, ашны куерак итеп салып куйдым. Бармаклары булмагач, ризыгын өстәленә алып килеп бирәләр. Ашыкмый ашады ул. Яшәр урыны бар үзенең, әмма акчасы җитми. Бармаклары булмауны исә, яшьлек хатасы, дип кенә әйтте. Салкында өшеткән.

Мохтаҗларны бирелдә кичке тугызга кадәр ашаталар икән. Лилия безне дә кыстады. Ризыктан өстен була алмадык. Сарык шулпасының тәме телеңне йотарлык! Чәйләре дә хуш исле!

... Ә язмышлар турында китап язарлык монда. Күз яшен чыгармасам да, йөрәк әчтән сулкылдады. Монда килгәннәрнең күбесе – әти-әнием яшендә. Димәк, куып чыгаручылар безнең буын була түгелме соң? Приюттагылар өчен бер уңайсызлансам, чиратка басып, ашарга кeтүчеләрне күреп, бер моңайдым. Кулларына тоттырган бер мандаринга ничек сөенгәнен күрсәгез иде аларның! Икешәр кисәк ипи, икешәр мандарин сузганда, берсен генә алалар. Үзләре кадерсезләнгән кешеләр башкаларга тормыш кадерен аңларга өйрәтә.

ЗӘЙНӘБ ФӘРХЕТДИНОВА:

«СӘХНӘ КЕШЕСЕНӘ БЕРВАКЫТТА ДА ҖИҢЕЛ БУЛМАДЫ»

Һәр заманда тамашачының яраткан җырчысы булып калу өчен нинди сыйфатлар кирәк? Татар җырчысы булу – үзеңне кысаларга кертү дигән сүзме? Ил-көн вакыйгалары иҗатка ничек тәэсир итә? Татарстанның халык артисты Зәйнәб ФӘРХЕТДИНОВА белән әнә шул хакта сөйләштек.

«Татар-информ»

:: Заман кешене ничек үзгәртә?

– Замана бөтен кешеләргә, бигрәк тә безнең кебек совет заманында туучыларга, совет мәктәбендә укыганнарга тәэсир итә. Әниләр, без үскәндә, заманалар бигрәк үзгәрде инде, дип әйтә торганнар иде. Сугыш һәм сугыштан соңгы авырлыкларны күргән кешеләрнең тел төбен без ул чакта, бәлки, аңламаганбыздыр да. Рәхәт заманда яшисез, дип йомгаклап куюлары ул чакта, бәлки, елмаю тудыргандыр. Хәзер инде үзебез шул сүзләрне әйтәбез. Заман коточкыч тизлектә үзгәрә. Безнең буынга аның кайбер үзгәрешләрен кабул итү дә читенрәк. Ә кайберләренә, теләсәң дә, ияреп булмый. Бу җәһәттән мин яшьләрне күзәтергә яратам. Бу – алар заманы. Димәк, алардан күп нәрсәгә өйрәнеп була.

:: Үзгәрешләр иҗатка ничек тәэсир итә?

– Беренчедән кешеләрнең яшәешкә мөнәсәбәте үзгәрде. Әйтик, җырлы мәҗлесләр сирәгәйде, гомумән, мәҗлесләрдә җырлашып утырулар бетте диярлек. Туй мәҗлесләре тыйнакланды, яшьләр язылышалар гына, туй итмиләр. Вазгыять халык кәефенә тәэсир итми калмады, билгеле. Яшерен-батырын түгел, билләрне кысыбрак яши башладык. Ә иҗатның үзенә килсәк, кайбер темалардан баш тартырга туры килә. Күп кенә авторларга, мин бу җырны башкара алмыйм, дип тә әйтәм.

:: Сез сәхнәгә чыккан вакытлар белән хәзергене чагыштырсак, җырчыга танылу кайсы вакытта җиңелрәк иде?

– Чын мәгънәсендә сәхнә кешесенә ул вакытта да, хәзер дә җиңел түгел. Тыштан караганда, хәзер җиңелрәк кебек. Янәсе, радиога һәм телевидениегә бер языласың да, танылу килә. Кайберәүләр шулай уйлый да. Ә бу әле – эшнең башы гына. Башта күренәсең, халык игътибарын яулыйсың, аннары гомер буе шул игътибарны югалтмас өчен тырышасың.

> Хәзер мөмкинлекләр зур, тавышны да көчәйтеп, матурайтып була. Әмма аның нәтиҗәсе озакка түгел. Бер тапкыр шулай сәхнәгә чыгарга мөмкин. Ә бит сәхнәнең үз кагыйдәләре бар. Анда тавышның көчле булуы, энергетиканың тамашачыны яулап алуы кирәк. Дөрес, бер чыккач, сәхнә үзенә гел ымсындыра. Анда матур, анда бар нәрсә ялтырый. Сәхнәдә калу өчен иҗат кешесе булып туарга, аның белән яшәргә кирәк.

:: Беренче гастрольне хәтерлисезме?

– Мәдәният институтының беренче курсын тәмамлаган чак. Музыкант, композитор Марс Макаров, төркем туплап, безне Түбән Новгород якларына алып чыгып китте. Филармониянең яшь артисткасы буларак беренче гастрольләрем әнә шунда башланды. Минем ул чакта, булса, 2–3 җырым булгандыр, шулар белән ике атна чыгыш ясадым. Гастроль тормышын Марс абый белән башлап җибәрүемә мин бик шатмын. Талантлы музыкант белән сәхнәгә чыгып басу безнең кебек яшь башкаручыга ышаныч бирә, каушамыйсың, халык та җылы кабул итә. «Мәтрүшкәләр», «Кыр казлары» җырларын башкаруым истә. Без бит Әлфия апа Авзалова, Илһам Шакиров, Илфак Смаков кебек берничә генә җырчыны тыңлап үскән авыл балалары. Ә инде юлда йөрү, чыгышлар татар эстрадасының җырга да, талантларга да бай икәнен күрсәтте. Бу минем өчен яңа дөнья иде. Шуннан китте инде. Укулар башлангач, Тинчурин театры артистлары белән авылларга йөрдек. Минем холык алар компаниясен кабул итмәде. Дөресен әйткәндә, мин кыргыйрак идем. Аннары «Иделкәем» ансамбленә йөри башладым. Аның белән Уфада гастрольләрдә йөрдек. Хәйран гына остардык, авылларда мөстәкыйль чыгышлар ясый идек. Аннан Зөфәр белән очраштык, яңа төркем җыеп, чыгыш ясый башладык.

:: Дуэт белән чыгыш ясауны да сез популярлаштырдыгыз кебек.

– Ул елларда Хәйдәр Бигичев белән Зөһрә Сәхәбиеваның парлы чыгышларын бик яратып кабул итәләр иде. Без дә Зөфәр белән парлап чыгыш ясый башлагач, килеп рәхмәт әйтәләр иде. Күрәсең, парлап җырлаганда җыр төсмерләргә байый, мәгънәсе тагын да тирәнәя торгандыр.

:: Зөфәр абый белән дуэтларны хәзер дә сагынып көтәләр.

– Сагынмасыннар, концертларга килсеннәр. Концертларда бергә чыгыш ясыйбыз. Еш кына, тавышларыгыз туры килеп бетми, дип тә әйтәләр. Ул туры килеп бетәргә тиеш тә түгелдер. Без икебез ике төрле тавышлы булганга матур яңгырагандыр. Дуэт белән җырлауны туктатырга җыенмыйбыз, чөнки бу чыгышлар вакыт сынавын уңышлы узды. Хәзер дуэтлар бик күп, әмма барысын да отышлы дип әйтеп булмый. Кайберләре югалып кала, ник дигәндә, дуэт ул – бер-береңне тулыландыру да. Күпләрдә менә шунысы юк.

:: Улыгыз Булат белән дуэтны ничек кабул итәләр?

– Яшерен-батырын түгел, башта шикләнебрәк тотынган идек бу эшкә, ә инде тамашачының хуплавын тойгач, без дөрес юлда дигән фикер ныгыды. Безнең җырны җырлап, яздырып җибәрүчеләр дә бар. Бигрәк тә яшьләр ярата.

:: Репертуарыгыздагы заманга яраклашкан җырларны тамашачы ничек кабул итә?

– Мин бертөрлелекне гомумән яратмыйм, стильләрне дә үзгәртәм, һәрвакыт үзгәрүдә. Мин үземне барыбер иҗат өчен яралган кешедер дип уйлыйм. Әлбәттә, төрле вакытлар булды. Үземне гаиләгә багышлап, иҗат тукталып торган чакларны да кичерергә туры килде. Сәламәтлек аркасында да зур гына тәнәфес ясадым. Бар да яхшы булып, ниндидер бер штильгә килеп кергән чаклар да була. Андый чакта бернинди эш бармый. Эшләгәнең үзеңә кызыксыз булып кала һәм син эзләнә башлыйсың. Үзеңнән канәгать булмау янә «кабызып» җибәрә. Нәтиҗәдә яңа җырлар туа, яңа аһәңнәр табыла.

:: Хәзер бу җәһәттән мөмкинлекләр дә күбрәк инде.

– Алай дип әйтмәс идем. Чынлыкта мөмкинлекләр күп түгел, бигрәк тә татар сәхнәсендә. Татар җырчысына яшәү җиңел түгел. Без барыбыз да ниндидер бер вакуум эчендә, шунда татарлыгыбызны сакларга тырышабыз. Үзебезнең дөньябызны рус мохитеннән сакларга омтылып, русча да җырламыйбыз, бу яктан да чиклибез. Инде гастрольләрне күз алдына китерик. Татар җырчысы Россия буйлап концертлар куярга ниятли ди. Аның концертына билет бәясе рус артистларыннан күпкә түбән. Әмма бит ул татар сәнгатен читкә алып чыга икән, аны югары дәрәҗәдә күрсәтергә тырыша. Яхшы аранжировкалар яздыра, сәхнәгә, образларына зур чыгымнар тота. Саный башласаң, бу концертларның үзен акламаган чаклары да күп була. Шуңа үзләрен бүтән милләт сәнгатенә багышлаучылар да бик күп.

:: Тулаем рус программасына күчәм, дип игълан итүчеләр бар бит әле. Әйтик, менә Элвин Грей (Радик Юльякшин) шулай дигән иде дә, татар-башкорт эстрадасыннан чыгып бетә алмый.

– Элвин Грейны мин татар-башкорт эстрадасында зур юнәлеш дип саныйм. Ул – бик матур үрнәк. Продюсеры уңышлы образ уйлап тапкан, молодец. Элвин безнең сәнгать өчен начар эшләмәде, күпләргә уйланырга җим бирде, булдыклы икәнен раслады.

:: Аерылабыз, сәхнәдән китәм, өйләнешәбез кебек сүз чыгарып та тамашачы игътибарын яулауга ничек карыйсыз? Үзегез андый адымга бара алыр идегезме?

– Мин кешегә психологик йогынты ясау ысулын беркайчан да кулланмадым. Ә бу – психологик тәэсир итүнең бер төре. Ул – бүгенге чорның бер сыйфаты, интернет шаукымы. Кемнеңдер үзен әнә шул яктан да күрсәтәсе килә икән, эшләсен. Бәлки, ул шул яклап үзен аерылып торам дип уйлый торгандыр. Әлбәттә, мондый сүзләр беркадәр кызыксыну уятадыр, сүзгә ышанып, концертны барып караучылар да бардыр. Әмма залларны тутырырга ярдәм итә дип уйламыйм. Сәхнә кешесе әрсез булырга тиеш. Шушы сыйфат булмаса, сәхнәгә чыгуның кирәге дә юктыр. Менә бит әле җырлый белмәсә дә, барыбер менә, минеке хак дип, барыбер тырыша. Шулай инде, минеке яхшырак, дип мактамаса, аның тауарына кем күз салсын?! Әмма вакыт бар бит әле. Ул – төп бәяләүче. Үземнең андый шаукымнарга бирелгән булмады һәм булмас да. Мин аны энергетик вампирлык дип саныйм.

:: Ә менә киенү стилен үзгәртүне ничек кабул иттеләр?

– Имиджны үзгәртәм, әмма чама хисен югалтканым юк. Төрле фикерләр килеп ирешә, кемдер хуплый, кемдер бик каты бәрелә. Гомер буе бер урында калып

Блиц-сораштыру

– Бүгенге халәтегез нинди җырга туры килә?
– «Агыйделдә ак кораб...» дип җырлап килдем әле. Ул – минем әтинең җыры. Тавышы шундый шәп иде аның. «Ай әтиең җырчы булса», – дип соклана иде әни. Әни дә җырлый иде. Күршеләр, Мәрҗәнә апа шундый матур җырлый иде бит, дип искә алалар иде. Мин, җырчы булам, дигәч, әнинең, тамак туйдырырлык акча эшли алырсыңмы икән, балам, дип борчылганы истә. Әни тырыш, эшчән, турысын әйтә торган кеше иде. Мин алай әйтә алмыйм.

– Соңгы укыган китабыгыз?
– Лев Толстойның «Война и мир» романы.

– Тормышыгыз турында фильм төшерсәләр, ул ничек аталыр иде?
– «Бу бит – син!» Концерт программам да шулай атала.

– Холыктагы биш төп сыйфат?
– Тәвәккәллек, конфликтлы хәлләрне булдырмаска тырышу, тынычлыкны саклау, каударланмау, сабыр итү... Тынычлыкны гомергә эзләдем. Күрәсең, энергиям кайнап торадыр, шул ук вакытта тынычлыкны кулда тотарга тырыштым.

– Үкенечкә калган сыйфат?
– Үземне музыкант буларак үстерә алмадым. Кечкенәдән музыкаль инструментым булмады. Дөрес, бәләкәй чакта уенчык рояль күреп калдым, әмма бер атнадан ул да юкка чыкты. Әллә урладылар, әллә... Яңадан уен коралы алучы булмады.

– Бәхет ул – ...
– үз-үзеңне аңлый белү, үз юлыңны табу, шул юлыңның эчке дөньяң белән туры килүе.

булмаган кебек, бер үк образда гына калырга ярамый, алай булмый да ул. Һәр чор киенү рәвешенә, образларга үз чалымнарын өсти, аларга күз йомып булмый инде. Ә консерватив караш ул гомер-гомергә бар. Мин аны начар димим, ул да кирәк. Әмма артыкка китсә, ул да туйдырып җибәрә. Ә эзләнү юлыңны дәвам итү, тукталып калмау өчен кирәк.

:: Холкыгыз буенча сез нинди кеше?
– Һәр проблеманың да чишелеше бар. Мин әнә шулай дип яшим. Сәхнә дә бу җәһәттән чыныктыра. Төрле чак була бит, авырган килеш дә җырларга туры килә, кайгылы чагыңда да концертны чигереп булмый, авырлы чакта да чыгасың. Нинди генә хәл килеп туса да, яхшылыкка ышанасың. Мин, мөгаен, оптимисттыр. Безнең Зөфәр дә шундый.

:: Сәхнәгә беренче чыккан мәлләрдә, мөгаен, кемгәдер охшатып җырлау – гадәти хәлдер. Хәзер дә кемнәрдәдер Әлфия апа, Илһам абый, Салават аһәңнәре ишетелеп китә. Ә сез кемгәдер охшатып җырларга тырыша идегезме?
– Мөгаен, юктыр. Үзеңнекен булдырырга кирәк. Кабатлау булмагандыр дип уйлыйм. Әмма үскәндә «Кыр казлары артыннан» спектаклендә Исламия Мәхмүтованың җырлавына гашыйк идем. Аның артыннан кабатлап, аныңча җырларга тырышу да бар иде. Аның халыкчанлыгы күңелгә кереп калган. Нинди генә җыр башкарсам да, аның үзәгендә әнинең моңы, әбинең мөнәҗәтләре ятадыр, мөгаен. Тыңлап үсеп, шуларны дәвам итү бу.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

Ахыры. Башы 7 апрель санында >

РӘШИТ ФӘТХРАХМАНОВ

САКЛАУЧЫ ФӘРЕШТӘ

(ХИКӘЯ)

Сәләхетдин яхшы аңлады: малайга өмет дигән канат куймасаң, тормыш төбенә төшәчәк һәм шунда батачак. Иң җиңел юл: баланы уллыкка алып, тәрбияләп үстерү. Ләкин бу юл Сәләхетдин өчен бикле иде. Нахакка гаепләнеп, төрмәдә утырып чыкты ул. Хәзер аңа беркайда да эш бирмиләр. Малайны бирмәсләр дә бирмәсләр. Кичәге зекка кем, ышанып, бала тапшырсын? Бик сәләтле математика укытучысы югыйсә. Шәһәрдә лицейда укытты, укучылары ел саен олимпиадаларда җиңү яулыйлар иде. Көнчеләрнең арттан пычак кадаулары аркасында шушы хәлгә төште. Авылда берьялгызы терлек асрап, тегесен-монысын саткалап көн күрә. Малайны эзләп, монда килеп чыксалар, үзенә көн бетәчәген яхшы аңлый. Шулай да ятимгә бер атна бәйрәм ясарга булды ул. Үз янында калдырып торды. Яхшылап өйрәнде аны. Сынады. Балада эчкерсез күңел белән бергә математик фикерләү сәләте гаҗәп куәтле иде. Үзе дә бик яхшы математик булган Сәләхетдин яхшы аңлады: тормышта сирәк очрый торган экземплярны тартып чыгарган ул теге көнне сазлыктан. «Затлы нәселдән булырга тиеш бу бала, затлы нәселдән», – дип уйлап куя иде малай белән ныграк танышкан саен. Әтисе кем икән соң?! Төрмәдә күрде Сәләхетдин: зур ерткычлыклар кылып, таш капчыкка ябылганнар арасында әллә ниткән зур талант ияләре бар. Моның әтисе дә – шундый бер адәм актыгымы? Зур гөнаһны гадәти бер эшкә санап, алданган кызны авырлы килеш ташлап калдырганмы? Азат белән сөйләшкән саен, бу фикереннән кире кайта ир. Күңел сиземләве шуны әйтә: кара күңелле атадан мондый саф күңелле бала тумас. Кан үзен сиздерә ул. Бер сиздерми калмый.

Кире шәһәргә, балалар йортына китәргә туры киләчәген белгәч, малайның борыны салынды. Күзләреннән башта ике тамчы бәреп чыкты, аннан коелды гына яшьләр.

– Энем, тыңла: мин сиңа «өмет» дип аталган бер кырыс эксперимент турында сөйлим, – диде Сәләхетдин, аның башыннан сыйпап. – Курт Рихтер исемле Америка биологы үткәргән аны. Ул күселәрне яртылаш су белән тулы савытка салган. Күселәр унбиш минут йөзгәннәр, соңгы көчләренә кадәр исән калу өчен көрәшкәннәр. Әмма унбиш минуттан соң төпкә киткәннәр. Рихтер аларны үләргә җиткәндә генә тартып чыгарган һәм, ял иттереп, яңадан шул ук савытка салган. Бу юлы инде көрәш 60 минутка сузылган. Авыр минутта ярдәм кулы сузылачагын аңлаган ерткычлар үзләрендә озаграк йөзәргә көч тапканнар. Аңлыйсыңмы эшнең нәрсәдә икәнен?

– Аңлыйм, – диде малай олыларча. – Өмет яшәргә көч бирә.

– Беркайчан да бирешмәскә! – диде Сәләхетдин абыйсы аңа балалар йортының ишеген ачып кертеп җибәргәндә. – Ә мин синең яныңа килеп йөрермен.

Чынлап та, бу олы йөрәкле кешенең ярдәмен гел тоеп яшәде Азат. Тугызынчы классны тәмамлагач, аларны профессиональ-техник колледжларга укырга озатачаклар иде. Детдомда кагыйдә шундый. Азат исә үзенең укырга сәләте барлыгын раслап өлгергән: математика буенча республика олимпиадасында җиңгән, россиякүләм ярышта призер булган иде. Сәләхетдин абыйсы, аны яклап, Президентка кадәр барып җитте. Сәләтле балалар өчен оештырылган махсус мәктәпкә урнаштырды. Сәләхетдин үзе дә шул мәктәптә укыта хәзер. Нахакка гаепләнүен исбатлап, аклануга иреште ул.

– Әтиең белән очрашмый калмассың, энем. Аның белән очрашканда: «Әти, мин менә кем булдым!» – дип әйтерлек булсын, – дигән иде аңа абыйсы. Әтисен тапмады әле Азат. «Кем булдым!» – дигән сүзне әйтерлек булып килә. Атаклы академик Шәйдуллинның фатирына диссертациясенең кулъязмасын күтәреп барышы. Хәлим Шәйдуллиннан фатиха алса, аңа докторлык дәрәҗәсе елмаячак...

...Хәлим югары уку йортын тәмамлап килгән көннәрдә беренче тапкыр җаны-тәне белән гашыйк булды. Пединститут дипломы алып йөрүче Гөлзәйнәп тә егетне бер күрүдә ошатты. Ошатты гынамы соң? Яшьләр икесе дә бер-берсеннән күзләрен ала алмаслык хәлдә иделәр. Хәлимнең тормышка планнары җитди иде. Җәен ул ике айлык хәрби сборда булачак. Аннан офицер званиесе алып кайтачак. Көзгә аспирантурага керәчәк. Аспирантурага керүне тагын бер ел көтәргә туры киләчәген, хәрби сбор һәм офицерлыкның үзенә бөтенләй эләкмәсен каян белсен егет! Язмышның борылышлары бик катлаулы була кайчак. Майлаган кебек кенә бармый ла тормыш арбасы. Тик ул чакта мондый фәлсәфә – тормыш катлаулылыклары турындагы уйлар егетнең башына бер дә керми иде. Хәрби сборга китәрмен дә, Гөлзәйнәпнең башын бүтән егет әйләндерер, дигән курку йөрәген тәмам биләде. Кызны ничек тә үзенеке итеп куясы килә, әмма туйлап йөрергә вакыт бик аз. Соңгы курста укыганда, Гөлзәйнәпнең әти-әнисе кинәт бер-бер артлы үлеп киткәннәр икән. Кияүгә чыгу-чыкмау мәсьәләсен кызга үзенә генә хәл итәргә туры киләчәк, димәк. Егет тимерне кызуында сугарга булды: кызга, никах укытыйк та бергә яши башлыйк, туйны көзгә итәрбез, дигән тәкъдим ясады. Танышканнарына бер генә атна иде, шулай да бер-берсен гомер буе белгән кебек тойдылар. Кыз артык ялындырмады, риза булды. Ерак бер авылда укытып йөргәнче, Казанда сөйгәнең белән яшәү күпкә яхшырак бит инде. Хәлимнең эчкерсез егет булуы бер сөйләшүдә аңларлык. Шулай уйлады Гөлзәйнәп. Казан мәчетендә никах укытуны оештыру артык катлаулы булмады. Никахтан соң өч көн Казанда яшибез дә Азнакайга егетнең әти-әнисе янына кайтып китәбез, дип уйладылар. Үз гомерләрендә беренче һәм соңгы кичне Гөлзәйнәпнең тулай торактагы инде комендантка тапшырылган бүлмәсендә кундылар. Хәлим яшәгән тулай торакта ремонт башланган иде. Ни өчен шулай ашыктылар? Никахны Азнакайда әти-әни янына кайтып укытып булмый идеме? Менә бу сорауларга Хәлим үзенең академик башы белән әле дә җавап таба алмый.

Зөфаф кичәсенең иртәсендә Хәлим, Азнакай автобусына билетлар алырга дип, автовокзалга китте. Хәзерге кебек кеше саен машина юк иде әле ул чакта. Автобуска билетны автовокзалда озак чират торып аласы. Гөлзәйнәп өстәл җыештырып калды, Хәлим чыгып китте шулай. Аһ, белсә икән Хәлим гомерендә Гөлзәйнәпне соңгы күрүе икәнен! Аягын да атламас иде сылуыннан башка.

Татарстан урамы аша чыкканда, машина бәрдерде яшь кияүне. Ни булганын да аңышмый калды. Бер атнадан соң гына хастаханә ятагында комадан чыгып аңына килде. Башта ни булганын аңламый торды. Аңлаганнан соң, үзәге өзелеп төшкәндәй булды. Гөлзәйнәп нишли икән анда?! Ул бит берни дә белми! Хәлим турында хыянәтче дип уйладымы икән? Их, хәзерге кебек кесә телефоннары булса иде ул чакта. Шалтыратыр да, аңлашырлар да иде. Хәлимнең адресын да белми бит яшь хатыны. Бер генә юл кала: савыкканнан соң, Акчурага кайтып, Гөлзәйнәпне эзләп табу. Кызның кайсыдыр районга бер авылга эшкә билгеләнүен белә иде. Төгәл сорашырга өлгермәде. Бергә китәбез, кызның яңа эш урыны бөтенләй кирәк булмас, дип уйладылар ич. Куллар каләм тотарлык булганчы, көз җитте. Акчурага хат язып салды, җавап килмәде. Хәлим, аңына килгәч тә, хастаханәдән чыгучы бер агайга Гөлзәйнәп бүлмәсенә сугылуын, үз хәлен аңлатуын үтенгән иде үтенүен. Тик, күрәсең, яшь хатын, өметсезлеккә биреләп, авылына кайтып киткәндер. Аймылыш булдылар да куйдылар. Хәлим, савыгып чыгып, Акчурада Гөлзәйнәпнең әти-әнисе йортының капкасын каккан-да, юлларга буран кар салган, кышның кыска төне кичкә авышып бара иде инде. Акчурада ул чакта да кеше бик аз яши иде. Гөлзәйнәпнең кая урнашуын белүче табылмады. Әти-әнисе исән булмагач, кыз күрәсең, туган йортка кайтып та тормаган. Кызны Акчурадан эзләүдән файда юклыгын аңлады шунда Хәлим. Чит өлкә авылы шул бу, Татарстан да түгел. Шулай да еллар үткәч, өр-яңа япон машинасы алгач, ул яклардан бер әйләнде ул тагын. Җәй иде. Акчура юлында ләмгә баткан бер малайны җитәкләп, иске машинасына утыртырга килгән бер агайны күрүе истә калган. Каян белсен Хәлим иномаркада үз улы яныннан выжылдап үтүен?!

Менә алар, ике галим, берсе – дөньяга мәшһүр академик, икенчесе – яңа гына гыйльми дәрәҗә алган фән докторы, күп еллардан соң Акчурага кайтып баралар.

– Әти, шушында туктап алыйк әле, – диде Азат әтисенә. – Ун яшемдә менә шушы төштә Сәләхетдин абый мине сазлыктан тартып чыгарды. Әнием кыяфәтендәге фәрештә коткаруын үтенгән иде.

Хәлимнең башына тагын шаулап кан менде. Йөрәген кисеп, үкенеч тойгысы үтте. Алда әле аны яңа тетрәнүләр көтә. Ике сәгатьтән соң алар Акчурада Гөлзәйнәп яшәгән йортның ишеген ачып керәчәкләр. Сандыктан Гөлзәйнәпнең көндәлеген табачаклар. Күз яшьләре белән сугарылган кулъязмасын укыячаклар. Хәлим кызның, аны югалткач, ничек итеп тулай торакта Хәлим яшәгән бүлмәнең ишеген шакып елап торганын, алдануын белгәч, Бауман урамнарында үксеп йөрүен, уйнаштан бала тапкан өчен мәктәптән куылып, туган йортына кайтып егылуын беләчәк. Газаплы тормышның авыр көндәлеген укыячак. Гомеренең соңгы көненә кадәр язган Гөлзәйнәп. Соңгы җөмләсе: «Бүген тынычланырмын кебек. Ак киемле затлар мине алырга килделәр инде. Я Раббым, улымның иминлеген, әтисе белән очрашуын сиңа тапшырдым. Әтисе каршына башын горур тотып барсын иде. Әшһәдү әл-ләә иләһә илләллаһ вә әшһәдү әннә Мүхәммәдәр-рәсүлуллаһ», – дип тәмамланган.

Ә СИН БЕЛӘ ИДЕҢМЕ?

Бөек рәссам Пабло Пикассоның тулы исеме:
Пабло Диего Хосе Франсиско де Паула Хуан Непомусено Мария де лос Ремедиос Сиприано де ла Сантисима Тринидад Мартир Патрисио Руис-и-Пикассо.

Әз-мәз мәзәк

– Нинди ел хәзер?
– Авыр ел.

* * *

– Югары белемеңнең кирәге чыктымы?
– Бернинчә тапкыр сораштыруларда «белемем югары» дип җавап бирдем.

* * *

– Сине хатының белән кем таныштырды?
– Үзебез таныштык, берәүне дә гаепләмим.

Хәтта ватык сәгать тә тәүлегенә ике тапкыр дөрес вакытны күрсәтә.

Сканворд җаваплары

Горизонталь: тамаша, һади, Сая, Рэнделл, Алеппо, ролик, свояк, вак, Сөн, багги, Стёпа, шикле, хат, ре, ант, Анжи, аулау, ат, аяз, Шамуазо, вакыт, ТНВ, лә, аз, Рәбига, өмет, Зара, Тха, Шәкүр, мөәзин, Киа, әти, ил, ал, Вәлиева, ар.

Вертикаль: арба, аваз, азан, ерганак, аш, психиатр, Таһиров, Әлки, Ив, остаз, әләк, мәданият, Тикрит, кёрлинг, имин, сер, ватык, Авзалова, Уш, Илава, Ялла, алдама, лар, Икшермә, СКА, Алмаз, Гөлназ, нетто, тән.

КАТНАШ АЗЫК, АШЛЫК

ФИНИШ БРОЙЛЕРЫ өчен
(26 көнлек һәм аннан зуррак бройлерлар өчен)

КАТНАШ АЗЫК

Глазов һәм Богданович шәһәрләре заводларында җитештерелгән терлек азыгын (бройлерлар, йомырка салучы тавыклар, бытбылдыклар, йорт куяннары, мөгезле эре терлек, күркәләр өчен), шулай ук аертылмаган сөтне алыштыручы ризык, мөгезле эре терлек өчен тоз һ.б. сайлап алу мөмкинлеге зур.

Казан, Техническая урамы, 15. **тел.: +792-704-99-706**

Чаллы, Магистральная урамы, 1а/1. **тел.: +792-767-27-366**

** сыер рәсеме төшерелгән сары баннерны эзләгез!*

Безнең сайт: agroline1.ru

реклама



Беләсең килсә...

1 Зөлфәт Хәкимнең «Мылтык» әсәрендә төп геройның исеме:
а) Али;
б) Уел;
в) Вил.

2 «Тундра» моделе нинди автомобиль маркасына карый?
а) «Тойота»;
б) «Ниссан»;
в) «Шевроле».

3 Күп тавышлы музыкаль әсәрдәге барлык партияләр җыелмасы ул –
а) увертюра;
б) партитура;
в) тесситура.

4 Танылган композитор Михаил Глинканың әнисе нинди фамилиядә булган?
а) Глинка-Зайка;
б) Глинка-Земляника;
в) Глинка-Земелька.

Җаваплар: 1. б); 2. а); 3. б); 4. в).

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррирнең беренче урынбасары – ХӨСНУЛЛИН Илнар Хәлил улы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 14278 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 253

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+